


# НӘҖИБӘ САФИНА

## *Кан хәтере*





НӘҖИБӘ
САФИНА

# *Кан хәтере*

*Шигырьләр*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2009

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
С24

**Сафина, Н.Ә.**

С24 Кан хәтере : шигырьләр / Нәҗибә Сафина. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2009. — 175 б.
ISBN 978-5-298-01842-5

Шагыйрәнең әлеге китабына туган туфрак, халык, милләт язмышы, мәхәббәт турындагы лирик-фәлсәфи шигырьләре тупланды.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01842-5
© Татарстан китап нәшрияты, 2009
© Сафина Н.Ә., 2009

I

*Бәхәсләшмим: җан — мәңгелек.*
*Җан сатмаганнар элек.*
*Бүген шул җан да товар, —*
*Фанилык җаннар да бар.*

* * *

Кан бар, җан бар —
Ә кан мәңге хәтерле.
Мәңгелекне юк итмичә
Җуеп булмый хәтерне.

Мәңгелекне, йә, кайсыгыз
җиңә ала?
Йә вакытны арбасына
җигә ала?
Илләр, таулар, полюслары
күчәр дә...
Кан хәтере җирне тота
күчәрдә.

## БОЛГАР БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

Эй-һей-һей-һей!
Эй-һей-һей-һей!
Болгар ул даламыни?
Сәерсенеп карамагыз,
Мин сабый баламыни?..

Мин Болгарның бөек кала
Икәнен белгән идем.
Авып калган тарихымны
Күрергә килгән идем...

Миннән курыккан шикелле
Чабышалар кылганнар.
Әйтерсең алар бу җирдә
Ярамас эш кылганнар...

Туктагыз, әй, кылганнарым!
Болгар җиле, әй, тукта! —
Болгарның югалуында
Нәкъ сезнең гаеп юк та.

Берни дә эзсез югалмый —
Яныптбетмәгән төрбә.
Җир асты юлларың, Болгар,
Әйди тарихны үргә.

Туфрагыңа табаннарым
Кагылуга тойдым бит, —
Эндәште Болгар ташлары:
«Бабаң канын койды», — дип.

Монда үлән, монда туфрак,
Һәр каккан казык сөйли.
Монда җилләр үз илендә, —
Бер сөйли дә бер көйли.

Кылганнар әйтерсең инде
Үксеп арыган бала:
«Батырларның каны бездә
Гасырлар буе яна».

Үләннәр шулай эндәшә,
Ыңгырашалар ташлар:
«Безгә бәрелеп ярылды,
Аһ, нинди, нинди башлар...»

Дулкыннар шавын ишетәм, —
Сүнмәс хәтер суларда.
Баскыннар уйлаганнардыр:
Тынар, шаулар-шаулар да.

Су, туфрак, үлән, таш сөйли:
«Без дәүләт идек, кала.
Дәүләтле чагыңны әллә
Сагынмыйсыңмы, бала?

Без кала диварларына
Кабаттан кайтыр идек.
Милләтнең күтәрелешен,
Бәхетен татыр идек...»

Эй–һей–һей–һей! Үз җиреңә
Иңгәнсең икән, Болгар.
Бакча урыннарын тоеп,
Сайрап тора былбыллар.

Китмәгән хәтта кошлары —
Кешесе китәмени?!
Үз дәүләтен ташлап китеп,
Ул ятим итәмени?!

Без килдек. Җиргә иңгәннәр!
Без ишетәбез сезне:
«Изге кала торгызылсын!» —
Сез әйтәсез бу сүзне.

Күз алдымда — манара, ай,
Җанлана урамнарың.
«Төзегез, без монда!» — диеп
Пышылдый урманнарың.

Тукта, җил! Шаулама, дулкын! —
Изге калам калыкты!
Тарихтан җуя алмаслар
Хәтере исән халыкны!

## ТӨЕН

*(Россиядә халык санын алудан соң бер уйлану)*

Төелә халык, төелә
Империя көенә.
Империя куштаннары
Шул төенгә сөенә.

Чишелмәслек итеп төйнәп,
Чаптырмакчы булалар.
Чапканнарны тагын бер кат
Яптырмакчы булалар.

Үз-үзеннән китмәгәнне
Анда күптән сөймиләр.
Җанга төен төйнәр өчен
Менә ничек сөйлиләр:

«Теле, дине бер булса да,
Булсыннар ике халык.
Буталсыннар, комлы суда
Без тотучылар балык.

Урап һәм убып алабыз,
Кыеп алабыз җанын.
Төшләренә дә кермәсен
Үзләре булган чагы.

Тарих кабатлана бит ул –
Тагы үз эшен эшләр.
Бер якны кулда тоталсак,
Тагын пешәчәк эшләр».

Җан кадәр җанны пешереп
Кем ашарга җыена?
Идел-Урал туфрагында
Үзең булу тыела...

Юкса Идел белән Урал
Тирән дә, биек тә бит.
Милләтебез ошбу җирдә
Борынгы, бөек тә бит...

Ача алса әгәр күзен,
Күреп алачак үзен.
Томаламасаң авызын,
Ярып әйтәчәк сүзен.

Әле башка баскан аяк,
Сыртка сугылган таяк.
Телгә салынган балта,
Аякта — богау, атла!

Шул халәттә тора бүген
Татар Башкортстанда.
Үзе булып яши алмый,
Әллә язган һуштан да?

«Тирмә, — диләр, — туган йортың,» —
Татар ышанган була.
Гармун тартмый, ул курайга
Өргән, мышнаган була.

Төелә халык, төелә
Империя көенә.
Өзгәләнә ялгыз гармун
«Кара урман» көенә...

## ҮЗ ЯГЫНА БОРА

Хаклык эзләп халык ханга барган,
Хаклык эзләп барган хаҗга да.
Халык белән халык арасына
Ялган сыя алмый азга да.

Капчыктагы без генә түгел ул,
Гасырларны тишеп кайта бит.
Алтыннарны ваклап бетерәләр,
Хаклык бөтен килеш ята бит.

Бөтен килеш ул бөтереп ала
Ялагайны йә шул явызны.
Әйттермәскә һаман богаулыйлар
Кул-аякны, хәтта авызны.

Авызларга йозак салынгач шул,
Халык бераз дәшә алмый тора.
Хаклык дигән ачкыч, барыбер кайтып,
Йозакларны үз ягына бора.

## БУЛУЫ КЫЙММӘТ!

«Син үзеңнең зурлыгыңны
бел», — диләр миңа.
«Мин — зур!» — дисәм, кычкыралар:
«Ни җитми сиңа?»

Ә миңа бит зурлык түгел,
милләтем кирәк.
Ул булса, яшәячәкбез, —
булуы кыйммәт!

## ӘВЕРЕЛЕШ ЧОРЫ

Татар җаны, инде синең өчен
Әверелеш чоры күптән үткән.
Татар җаны инде гәүдәсеннән
Үзен–үзе ничә тапкыр түккән...

Агымсулар булып аккан ул җан,
Давыл булып күккә күтәрелгән.
Каф таулары булып торып баскан,
Әллә ничә тапкыр түнтәрелгән.

Кыр казлары булып очкан ул җан,
Йорт казлары булып җиргә төшкән.
Язда канат исе килә, диләр, —
Кыр казында татар җаны икән.

Әмма әверелергә кирәк әле,
Әверелергә кирәк чуерташка.
Таш булырга, баш булырга кирәк
Безгә Хода биргән зур язмышка!

Мәңгелектән шулай аерылмаска!

## ЯҢА ГУЛАГ

Уйларга күптән вакыт,
Милләтнең җаны ватык.

Күңелгә килгән ике сүз
Җанны тетрәтте,
Кунак — ГУЛАГ, ГУЛАГ — кунак —
Моны кем әйтте?

Туксан яшьлек бабай әйтте,
Сакалын сыйпап:
«Заманалар без кунакны
Китте шул сыйлап.

Фани дөньяда кунакта
Булдык ГУЛАГта.
Кайттык илгә, инде илдә
Хәлләр уйлата.

Җитте вакыт, әйтеп китәм
Әйтер сүземне:
Әй, кешеләр, яшәмәгез
Тик йомып күзне».

Татар милләтен таптарга
Полигон ачып,
Башкорт артында торалар
Башкалар качып.

Игезәктән ике милләт
Ясамакчылар,
Ялган тарихны ялганга
Ялгамакчылар.

Хак сүзне әйтер галимнәр,
Эндәшәм сезгә:
«Ничә гасыр ачы төтен
Сылана күзгә».

Ильич киңәйткән биләмә –
Бүгенге ГУЛАГ...
Анда татар шундый хәлдә,
Карасаң, уйлап...

## ӨМЕТ КӨНЕН БИЛГЕЛӘҮ

Әй, тантана кирәк миңа,
Бирегез миңа шатлык!
Әйтегез: «Югалтканны без
Таптык, — дип, — кабат таптык!»

Милләтнең бәйсезлек алган
Көне, сәгате, диегез!
Бүгеннән безнең станда
Барлык милләтләр тигез!

Әйтмәгез, сүзләрне юкка
Сипмәгез әле җилгә!
Табаннарым басып тора
Татардан калган көлгә.

Әле бүгенге бәйрәмнең
Исеменнән куркалар.
Күпләр өчен без — чаплашка,
Күпләр өчен — туркалар.

Бар максат — кысып-баскалап
Кечерәйтү бәйрәмне.
Бәйсезлек көне, күрегез,
Инде нигә әйләнде?

Карагыз, дивар катларын —
Язылмаган ни генә...
Шәһәр көне, сәфәр көне...
Бар да бар, җаныбызда тик
Яралардан җөй генә.

Әйтергә һич тә ярамый
«Бәйсезлек» дигән сүзне —
Әзерләр телне кисәргә,
Каплап куярга күзне...

Бүгенге бәйрәм, беләбез,
Әлегә шартлы гына.
Килер чын бәйрәмебезгә
Әзерләү шартны гына.

Бихисап бәйләрне безгә
Чишәргә кирәк әле,
Комнан, колдан арканнарны
Ишәргә кирәк әле...

Күз яше тулы күлләрне
Күккә асарга кирәк,
Гөрзиләрдән бумеранг
Әле ясарга кирәк.
Ә хәзергә бу эшләргә
Әзерләр әле сирәк.

Бер гомер түгел, дүрт гасыр
Чишелмәделәр бәйләр.
Бәлки, киләсе буыннар
Чишү юлларын шәйләр.

Шундый өмет тулы көн бу —
Һәр җанга өмет иңсен.
Җаныбыздагы коллыкны
Хөррият нуры җиңсен!

* * *

Бала туа, тибрәтергә җыр кирәк.
Ә бераздан тәпи басар җир кирәк.
Кеше китә — озатырга дога-җыр,
Мәңгелеккә башын салыр соңгы җир.

## ИЛЕГҮ

Һич төкәнмәс түземлекләр биргән
Хода кешегә.
«Яшәү!» диеп ничә гасыр ул Себердә күшегә.

Тыктылар ничә миллионын
фашизмның авызына.
Җиңү уты килер көннәр өчен диеп кабызыла.

Әфган җирендә башларын салдылар
безнең ирләр.
Инде буйсынырга тиеш чечен
яшәгән җирләр...

Чехы, сербы, словагы, әфган, чечен — берсе дә
Туган җиреннән китмәде, янган утка керсә дә.

Һич төкәнмәс түземлекләр биргән
Хода кешегә.
Туган җирендә килмешәк булып инде
күшегә...

Эшләп тә тамагы туймый, сугышып та иле юк.
«Русия» дигән идолның ни тарих, ни йөзе юк...

Кармана ул үрмәкүчтәй, колларының саны юк.
Нәрсә йөз, тел, кыйбла, иман?
Ул мәлгуньнең җаны юк.

Җансыз белән ничек җанлы төзи алсын
килешү?
Ишетелә дөнья буйлап бу гыйбрәттән көлешү.

Тарихын да алдан күрү мөмкинлеге калмагач,
Гел агулы алма бирә анда үскән алмагач.

Алмалары хәтта алтын булса да, ашамагыз!
Изге җирдә шул мәлгуньдәй
төмугны ясамагыз!

Иман, кыйбла, туган телең,
туган җир булса гына,
Бәхет гөле чәчәк атыр гаилә бусагаңда.

Илең барлыгын аңларсың, бары тик
шул чагында!

## ДУЛКЫН КИРӘК

Үз телеңдә ярып әйталмыйсың,
Үз илеңдә тотык шикелле.
Үткән гасырда да әйталмадың,
«Яңа гасыр»да икеле!

*Роберт Әхмәтҗанов*

Шөбһә салдың күңелемә,
Ачуымны китердең.
Өметне өзмәкче була
Синең шушы фикерең.

Үткән гасыр Тукайлы ул —
Ул әйтмәгәнме сүзен?
Ярты гасыр өзгәләнеп
Кычкырмыйсыңмы үзең?

Үткән гасыр Бабичлы ул,
Такташлы, Гафурилы,
Алишлы ул, Җәлилле —
Татар сүзе дәлилле!

Тик сүзен әйтә белсә дә,
Менә алмый дулкынга,
Аягын-кулын, рухын
Богауларда тотканга.

Ни кирәген беләсең бит —
Кирәк татар дулкыны!
Дулкынсызлык — туган телне
Буып торган упкын ул.

Дулкын үткәргеч йөрәкләр
Чыдар тагы күпмегә?
Дулкын үткәргеч корама
Тора юкса чүп кенә...

Дөнья гизәр дулкын кирәк
Татар шигыренә дә.
Шул дулкынны даулау кирәк
Татар шагыйренә дә.

Үз телендә әйтә татар,
Әйткән, әйтсен нык сүзен!
Милли горурлык ни-нәмә? —
Белмәгәнгә юк сүзем.

## ИҢ ОЛЫ КОРАЛ

Туган телгә көн бирелде,
Печәнгә биргән кебек.
Еллык тел җыеп калырга
Булса иде өлгереп...

Ел әйләнәгә җитәрлек
Телне җыеп калырга,
Ничә гасыр югалтканны
Бер көндәме алырга?

Ул бит мал печәне түгел,
Киптереп өелергә.
Кипкән телдән сүз чыкмый дип
Яшькәме төелергә?!

Үзең белән бергә туган,
Һәр көндә дөнья куган,
Кайгы-шатлыкларга манып,
Җаннарга уйны уйган

Тел генә туган тел була,
Түгел бер көнлек хәтер,
Бәйрәм көн тик татылырга
Ул түгел шәраб-хәмер.

Туган тел ул — җан ачкычы!
Ул — җаннарның ачысы!
Биеклеккә мену өчен
Һәр сүз — дөнья баскычы!

Үлемгә хөкем ителгән
Туган тел көнеме бу?
Бар иде, дип искә алып
Елашу көнеме бу?..

Кирәкми туган телемнең
Укыту көнен, елын!
Мин туган телемдә көләм,
Мин туган телдә елыйм!

Туган тел — тудыручы да,
Туган тел — туйдыручы!
Киләчәккә милләтенә
Ул нигез куйдыручы!

Типкәләнгән-тапталган тел
Ул бит безнең авызда!
Авызга типкәләүчегә
Кирәк богау — явызга!

Богау-сүс, мунчала, каеш,
Тимер чылбыр түгел ул!
Кеше горурлыгы булган
Чып-чын милли күңел ул!

Бары сөйләү генә кирәк,
Җырлау бишек җырларын.
Әлифба-Коръән укыту —
Моңа шаһит чорларым.

Телдән дә көчле коралның
Юк әле табылганы.
Тел — Ходайдан, ә калганы —
Шайтаннан тагылганы.

Тел көрәштерүләр — сәнгать,
Тел — тынычлык коралы!
Туган теленнән язганнар
Бар да — тарих корбаны...

Туган тел кадәр кодрәтне
Белми дөнья, кешелек.
Телдән язсак, тарих безне
Атар микән «Кеше» дип?!
Хурлыклы бәя калырмы
«Булган татар ише?» дип?!

## КОТЛЫЙМ

Чын бәхетле булу бармы?
Әллә уйнау гынамы?
Фәкать «шушы — бәхет диеп»
Әллә уйлау гынамы?

Җаның туктаусыз ялварып,
Күгәреп торса күңел —
Кояш та тутык икән,
Ай йөзе чытык икән.

Ерткаланган, ергаланган
Болыт кебек таралдым.
Тапталган, тапланган җирдәй,
Ахры, инде каралдым.

Яраларны кат-кат бәйлим,
Тышка чыгармыйм канны.
Бәйне тотмый, битлек япмый —
Кая куярга җанны?

Бәхет даулый — бәхет юк.
Тәхет даулый — тәхет юк.
Әй бу тынгысыз җанны,
Тәки сатты бит данны.

Инде миннән көләләр,
Теләгемне беләләр.
«Үрелмә, — диләр, — өскә!»
Тотып торалар көчкә.

«Күпме кирәк бәхет — ал,
Ләкин бәйдә, — диләр, — кал!»
Чыгып бара җан — тотмыйм...
Бәйсезлек белән котлыйм.

## ТӨРМӘЛӘР ҺӘМ ПАРЛАМЕНТЛАР...

Дөнья тора вөҗдан үлчәвендә, —
Тәлинкәләрендә ике төр зат:
Берсе — зиндан, берсе — парламент,
Кешеләр — бер, башка — орнамент.

Икесен дә бер иләктән иләп:
Җыелалар сайлап, сайланып.
Икесендә дә «әйбәт» утыралар
Һәм бетәләр тәмам майланып.

Үлчәү генә кайчак, тибрәнгәләп,
Төшергәләп тора «майлылар»ны.
Әле анда, әле монда салып,
Бутап кына тора «җайлылар»ны.

Дөнья үлчәүләре түнтәрелә,
Тәлинкәнең монсы күтәрелә.
Вөҗдансызлар төрмәләргә түгел,
Инде парламентка үткәрелә.

Шундый заман килде, замандашым,
Сагынасыңдыр «анда» үткәнеңне?!
Кыйблаң очты, инде белмисеңдер
Кайсы тәлинкәне сүккәнеңне?!

Дөнья тора вөҗдан газабында,
Тәлинкәләрендә ике төр зат:
Сатканнар һәм сатылганнар алар,
Тик бер генә түгел, кабат-кабат.

## БЕЛҮ КИРӘК!

Беләсеңме җилнең нидән искәнен?
Беләсеңме күңел нидән төшкәнен?
Беләсеңме, ник әйләнә Кояш вә Җир?
Ник сөяләр бер-берләрен хатын-кыз, ир?
Белү кирәк!

Тукталмаса Җир шарының әйләнеше,
Өзелмәсә буыннарның бәйләнеше,
Үз вакытында килсә җиргә фасыллары,
Барлап торса кайсы киткән, кайсы барын.
Белү кирәк!

Җил исмәсә, яфрак төшми, беләсең бит.
Яфрак төшми көзләрнең дә киләсе юк.
Җил исмәсә, болытлар да күчмәячәк,
Болытлардан мамык карлар төшмәячәк.
Белү кирәк!

Ак карларга парлы эзләр салынмаса,
Шул көннәрне гашыйк парлар сагынмаса,
Күңелләрдә булмаячак бер хәрәкәт.
Шушы булыр төшенкелек вә һәлакәт.
Белү кирәк!

## КОШ ҺӘМ КЕШЕ

Кошлар сайрый.
Әллә сайрый гына?
Сагышлардан кош та үксидер.
Әллә кеше генә парын җуя,
Кошларда да ансыз үтмидер.

Кошлар оча.
Әллә кошларның да
Җәяүлесе юкмы, бар бит ул.
Тәвәләрнең иңрәүләрен тыңла —
Җәяүледә моң да зар бит ул.

Кош кабереез —
Әллә кешеләрнең
Каберләре һәрчак табыла?
Кошлар булып җиргә кайта кеше,
Оча алса кеше чагында.

## ЭЛЕК ҺӘМ ХӘЗЕР

Элек алай түгел иде,
Ә хәзер кара! —
Бер ир-ат артыннан ничә
Хатын-кыз бара!

Статистика буенча
Булса — унбиштер.
Йә, Җәбраил, бу хурлыкны
Күккә ирештер...

Элек алай түгел иде,
Ә хәзер кара! —
Җәмгыять, алга барам дип,
Гел артка бара...

## САННАН ҮЧ АЛУ ГЫНА

«Картаймыйсың, — диләр, —
Әле синең чәчләрең ак түгел».
Әйткән булалар да, димәк әле,
Ул сүзләр хак түгел.

Чәчләр алар буялганнар гына,
Чәчләрем ак инде.
Гайбәт сөйлиләрме минем хакта? —
Барысы да хак инде.

Уңганлыгым минем бик чамалы,
Ялкаулыгым көчле.
Мәхәббәтем эзләп йөри-йөри,
Сөйдем, ахры, өчне...

Минем хыял күге көткән сөю
Һаман табылмаган.
Йөрәк өчен яшьлек капкалары
Әле ябылмаган.

Шул йөрәккә иярмәкче булып
Буйыйм чәчне-кашны.
Әй, Мәхәббәт, нинди тылсым соң син,
Юләр иткән башны?!

Мәңгелеккә сикермәкче йөрәк —
Кызурак эшли.
Кан басымы һаман арта бара,
Уңмаган сан нишли?

Болай булсаң, саным, сине җирдә
Калдырам да китәм.
Синнән башка гына мәңгелектә
Максатыма җитәм!

Безнең сөю — ачылмаган бөре, —
Чәчәк атачак ул!
Күргәннәргә нур чәчәге булып
Җиргә кайтачак ул!

Картаймыйсың, диләр чәчне түгел,
Нурны күрүчеләр,
Мәхәббәт бөресен мәңгелеккә
Алып керүчеләр!

## УЯНГАЧ АҢЛАРСЫЗ...

Йоклаган җанга нур иңми.

Йоклыйлар төннәр буена,
Таңны да күрми алар.
Иртәнге кояш нурлары
Җаннарга керми кала.

«Йоклыйбыз йокы туйганчы», —
Дип, шуннан мактаналар.
«Рәхәт яшибез», — дип, шулай
Урында таптаналар.

Йоклыйлар, күзләре йомык
Гүзәллек-ямьнәренә.
Җаннары йомык, битараф
Дөньяның гамьнәренә.

«Бүген күрми калган кояш
Иртәгә чыгар», — диләр.
Йоклыйлар, әллә вакытны
Кирегә чигәр диләр.

Вакытлар кире чигенми,
Йомык җанга нур иңми.
Алышларга чыга күрмә,
Башлап үзеңне җиңми.

## ЧҮП ҮЛӘНЕ

Чүп үләне турында
Уйладым күптән түгел:
Баш идерә, тезләндерә,
Юк, бу арттыру түгел.

Чүп кешеләр алдына да
Кеше бик еш тезләнә.
Сизми кала, үзе шулчак
Шул чүпкә тигезләнә.

## САБЫРЛЫК

Сабыр савытларым тулды,
Инде ни хәлләр итим?

*Халык җырыннан*

...Сабыймын, тик үземне
Шәйли башлаган чагым.
Абындым тип-тигез җирдә,
Егылдым, тордым тагын.

Күз яшьләрем йодрык белән
Сөрттем, кара эз калды.
Колагымда әниемнән
«Сабыр!» дигән сүз калды.

...Үсмермен — инде сөюне
Шәйли башлаган чагым.
Һәркем йөреп такырайткан
Юлда абындым тагын.

Кабат тордым, күз яшьләрем
Кулларым белән сөрттем.
«Сабыр!» сүзен әллә күктән,
Әллә җирдән ишеттем.

Тора, турая алганга
Бүләк итептер инде
Язмыш миңа тагы сөю,
Тагы сынау китерде.

Тау дип табынган сөюем
Булган ич түмгәк кенә.
Бәгырькәем дип кочканым
Булган ич күлмәк кенә...

...Газап татып ана булу
Хисен аңлаган дәвер:
Өзелеп төште бәгырем —
Ишеттем: «Сабыр! Сабыр!»

...Инде милләтем зурлыгын
Аңладым дисәм хәзер,
Тарих ялганы ачылып,
Өзелде кабат бәгырь.

Бизелгәнне, өзелгәнне
Ялгый килде сабырлык.
Көч кирәк бит егылмаска
Сабырлыклар табарлык.

Җир әйләнә, әйләнәбез, —
Аңладым вакытында:
Әйләнәбез бертуктаусыз
Сабырлык савытында.

...Кеше шуңа түзә алмый
Җырлап җибәрә беркөн:
«Сабыр савытларым тулды,
Инде ни хәлләр итим?»

* * *

Без дә китеп барабыз ул
Җирдән, «яшәдек» диеп.
Оҗмахка да керербезме,
Коллык богавын киеп?

Җан анда ирек алачак,
Җан чыгар савытыннан.
Тән анда да торып калыр
Чыгалмый табутыннан.

## МОҢ ЮЛЫ

*Казанның меңьеллыгына*

Әй, Казаным!
Меңьеллыгың, —
Үткәндәге якыныңдыр.
Бүген безнең йөрәкләрдә
Шул елларның ялкыныдыр.

Әй, Казаным!
Тарихың зур!
Әй, Казаным, тарихың — җыр.
Синең үткән мең елың да
Милләтемнең моң юлыдыр...

Әй, Казаным!
Тарихыңның
Бу сызыгы — тик мең елы.
Кол Галиле булу өчен
Үткәнсеңдер күпме юлны?!

Әй, Казаным!
Мең елгача
Аккан моңнар мең елгага.
Бер мең димим, ике димим, —
Кузгатып тарих тузанын
Бәгыреңә генә тимим.

Әй, Казаным!
Тарих көймәң
Кайсы диңгез төпләрендә?
Күпме шагыйрь, күпме галим
Китаплары йокләрендә?

Әй, Казаным!
Мең елың да
Сәфәр булды моң юлына.
Тарихларның күмелгәне,
Дәрьяларга түгелгәне,
Юк, еракта түгел әле...

Әй, Казаным!
Бу мең елың
Ачсын тарих капкаларын,
Ачкыч булсын ачар өчен.
Тарихыңның кояш көтеп,
Тирәндәрәк ятканнарын!

## КОНСТАНТА!

Хакимнәр биргән урыннар
Бик вакытлы,
Яклый калсаң, халыкны
Вә хакыйкатьне,
Ел дигәнең кыскарыр да
Сәгать булыр,
Гамәлләрең куылырга
Сәбәп булыр.

Киткән икән, дип, кайсылар
Сөенерләр.
Китеп өлгергән эзеңә
Төкерерләр.
Һәм әйтерләр: ул урыннан
Киткән инде.
Безгә кирәге, димәк ки,
Беткән инде.

Хаким биргән биеклеккә
Табынганнар,
Ялау өчен һәр заманда
Табанга зар.
Андыйларга Кеше дигән
Исем хәрәм.
Табаннары таптап йөргән
Туфрак әрәм.

Кайберәүләр, сикерсә дә,
Очтым, диләр.
Кеше икәнен онытып,
Кошмын, диләр.
Хаким биргән урын — читлек
Кош өчен дә.
Сак булыгыз: бу хакыйкать
Гел көчендә!

## КЫЧКЫРАМ!

Берәү килде: «Син тагын да сүгенмә инде», —
диде.
Ә мин аңа: «Син тагын да чигенмә инде», —
дидем.

«Кычкыруда хикмәт юк», — ди, юк,
мине ышандырмый.
Реклама ясаучылар кычкырмый һич
эш кырмый.

Милләтем, кая барасың?!
Ай-һай, ерагайгансың...
Кычкырам, аера бел, дип, кибәк белән ярмасын!

Кычкырамын, пышылдамыйм,
әнә җил пышылдасын,
Милләтен, дәүләтен саткан еланнар
ысылдасын.

Кычкырып дәшәм туган тел,
асылын сатмаганга,
Туган тел, үткән, бүгеннең рухын саклаганга.

Иң олы бүләк тиешле, аңа лаек андыйлар,
Нигә миңа: «Дәшми генә янсаң,
әйдә, ян!» — диләр.

Андыйлар ай да кояштыр,
мин алар булалмыйм бит,
Җирне ташлап, илне ташлап,
җиһанга тулалмыйм бит.

Миңа тел биргән табигать:
«Сөйлә, җырла, кычкыр, — дип, —
Чарасын тап һәм ишеттер,
киләчәккә эш кыр!» — дип.

Тиргәнүдә хикмәт юктыр,
хикмәт — ишеттерүдә.
Бүген дә яшәргә кирәк, нигә кичектерергә?!

Анда җәннәт булыр,
диеп гамәл кормаганнарга,
Ходай бирер әле, диеп һич эш кырмаганнарга

Берни әзерләп тормыйлар,
сәбәп ит, булыр насыйп.
Кычкырам, әгәр дә шулай
җаннарны булса ачып.

Бикләнгән җаннарга дәшәм:
«Кайтыгыз үзегезгә!
Киләчәгебез мохтаҗ бит туган телдәге сүзгә!»

Карганмыйм да, тиргәнмим дә,
оран салам, тыңлагыз:
«Дәүләткә лаек халык без,
исбатламый тынмагыз!»

# ДӨНЬЯ КЕШЕ КӨТӘ

Бүген дөнья алтынчы миллиард
кешенең дөньяга килүен көтә.

*Радио хәбәреннән*

Җан туктаусыз сөйләп тора,
Ниндидер көй көйләп тора.
Җан дәшкәнне ишетергә
Кеше кирәк, Кеше генә,
Кеше кирәк, Кеше генә.

Җан ул сөйләп кенә тормый,
Бар дөньяга аваз сала.
Иңмәдеме җаннан җанга,
Аваз әрнү булып кала
Һәм бар дөньяга тарала.

Тутыра ул тирә-юньне,
Килеп баса ике иңне.
Күтәрелми бер эшкә кул,
Тартып тора ике җиңне,
Буталып тора уң һәм сул.

Җан дәшкәндә ишетергә,
Хисләремне иш итәргә
Кирәк миңа Кеше генә,
Кеше генә, Кеше генә.

Җан туктаусыз Кеше көтә,
Бу ялгызлык җанны өтә.
Алтынчы миллиард кешесен
Инде бүген дөнья көтә.

Кешесезлек җанны өтә...

## ЧЫГУ ЮЛЫ

Яулап алдым бөек дөньяны мин,
Тик ул дөнья һаман тар калды.
...Усал илләрне мин буйсындырдым,
Миңа буйсынмаган яр калды.

*Зөлфәт*

Миңа буйсындыру кирәк түгел,
Буйсынганнарны мин яратмыйм.
Ике ярын үзе ясый елга,
Ярларым юк, диеп зар атмый.

Кирәк түгел миңа буйсындыру,
Буйсынган җил инде җил түгел.
Буйсынган ил тулы коллар гына,
Буйсынган ил инде ил түгел.

Сынган сыннан чыгып китә ул җан,
Миңа җансыз гәүдә кирәкме?
Сынган ил дә, сынган гөл дә мәет,
Сынганнарда йөрәк йөрәкме?

Тарлыкларга чыдый алмый җаннар
Кычкыргандыр, бәлки: «Тар! Тар!» — дип.
Шуңа күрә, бәлки, тарих безне
Атагандыр әле татар дип...

Әй талпынды җаным азатлыкка,
Җаным өчен саным тар калды.
Азат иттем җанны читлегеннән, —
Мин үлмәдем, саным таркалды.

## КАЛКЫНА

Дөнья шундый:
Һич тә белеп булмый
Кай тарафтан гөрзи төшәсен.
Таянырлык талың булмадымы,
Җилләргә дә сыгылып төшәсең.

Таяныр тал,
Әйе, нәфис яр ул.
Таянычың — якын дусларың.
Абайламый ябырылды фашист:
Таянырлык нокта гына кирәк,
Әйләндерәм диеп Җир шарын.

Илгә килгән
Фашист яуларын да
Без, таяныч булгач, талкыдык.
Фашист итегенең хурлыгын да,
Җиңү шатлыгын да татыдык...

Көтмәгәндә
Яңа афәт бүген
Калкып чыга илнең эченнән,
Безне кыйратырга бу халыкның
Инде килмәс, диеп, көченнән.

Тик ялгыша,
Нык ялгыша фашист.
Без таяныр таллар — исәннәр!
Без таяныр нокта — туган туфрак,
Ни күрәсен белсен килгәннәр!

Тереклекне
Без үтереп түгел,
Яшәтүче иген үстереп.
Таянырдай сандугачлы таллар,
Туган туфрак безгә чын ирек.

Илгә килгән
Башка килгән түгел,
Ул афәтне күмәк ил күмә.
Тимә, фашист, туган туфрагыма,
Туган телгә, минем иркемә!

Мин — хатын-кыз,
Беләм карынымда
Ни өлгереп, кемнең туганын.
Дүрт-биш гасыр элек сугышып үлде
Минем өчен рухи туганым!

Дөнья шундый:
Рухи байлыкларны
Алыштырдылармы алтынга,
Сак булыгыз, димәк, ил өстенә
Фашист явы тагы калкына!

## ХӘТЕРЕ КАЙТКАННАРГА

Иелгән башны кылыч кисми.
*Мәкаль*

Әй-й-й-й!
Тын калыгыз да тыңлагыз!
Ни сөйли Кабан күле:
Дәшми торучылар тере,
Сөйләүчеләре үле?

Тын калыгыз да тыңлагыз! —
Ни сөйли кыйбла җиле:
Көннең батышына карап
Баручылары тиле?

Әй, тын кал да тыңла әле,
Кыелган татар җаны!
Кабан күлендә су түгел,
Тулышкан татар каны...

Идел ярында таш түгел,
Киселгән татар башы...
Идел безгә бертуктаусыз
Шул хакта хәбәр ташый:

Үз заманына тереләр
Хуҗа була алмаса,
Тудырган анасын, телен
Яклар ирләр калмаса,
Гафу итмәячәк Кабан,
Басачак илне Идел.
Тормаячак илдә дәүләт,
Без бит дәүләтле идек.

Һәр яфракка, һәр сабакка,
Һәр чеметем туфракка
Кагыла да уфтана җил:
Илем, җирем, суым, димә,
Булмый ул дәүләтсез ил!

Хәтереңә кайтсаң, халкым,
Башыңны имә тагы!
Башлар киселсә дә, исән
Баш имәгәннәр җаны!

## ХЫЯЛ ҺӘМ ЧЫНБАРЛЫК

Кто прошлое помянет,
тому глаз вон!

*Мәкаль*

«Үткән, үткән, эше беткән татарның.
Хәтерләсәң, күзеңә ут атармын.
Төртермен дә чыгарырмын күзеңне,
Җәһәннәмгә озатырмын үзеңне.

Кол хәлендә сүзен сөйләп ятармы?
Үткән–беткән азатлыгы татарның.
Кул–аягы калсын, әйдә, эшләргә.
Димәк, дәшмәсен өчен ни эшләргә?

Кисәргә кирәк, әлбәттә, телләрен,
Җәһәннәмгә озатырга кемнәрен.
Калганнарын җыр белән оетырга,
Шул рәвешчә, тик вакытны отарга.

Вакыт шундый, эшләячәк үз эшен.
Җуйгач инде телләре дә үз көчен,
Алар бүтән күтәрә алмас башларын,
Бүгенге күк җыермаслар кашларын».

Шундый хыял «олы агай» җанында.
Шул яңгырый бүген чиркәү чаңында.
Ишеттермәс өчен мәчет азанын,
Чиркәү белән тутыралар Казанны...

Хак булса, яңа Мәскәү урамын
Бизәячәк тугыз Хода храмы?!
Бу урамның музыкасы чаң булыр,
Татар гамәленнән алар аң булыр.

Илбашлары: «Ярар, — диләр, — салсыннар,
Килгәннәр икән, нишлисең, калсыннар.
Күпме кирәк, нефтесен дә алсыннар,
Ил чикләрен саклар өчен ялчы бар».

Менә шулай, милләттәшләр, тереклек,
Юкса бу җир ата-баба көле бит.
Хәтер сүнсә, сүнәчәк хәтта өмет.
«Шайтан!» дип торырлар бездән көлеп.

Шул хәлләргә калганчы уяныгыз!
Телем-илем, рухым диеп яныгыз!
Әләм итеп күтәрик туган телне!
Торгызу мөмкин шулай дәүләт-илне!

Мин башка чара... белмим инде...

## ӘЛЕГӘ БАШКАЧА

Бу дөньядан кеше булып китәм,
Мин ни булып кабат кайтырмын?
Мин, мөгаен, җирнең бу йөзенә
Бер калкулык булып ятармын...

Ул калкулык үсәр дә тау булыр,
Кыя үсеп чыгар ташлардан.
Җан-ташларны буйсындырмак булып,
Югарыга үрли башларлар...

Чәлпәрәмә тагы таш кителер,
Кеше тагы түбән тәгәрәр.
Күтәреләм диеп төшүләрнең
Бәһаләрен белсәкме әгәр...

Без беркайчан таулар булмас идек,
Җаннар катмас иде таш булып.
Кеше бер дә ләззәт тапмас иде,
Кеше башларына баш булып...

## ӘГӘР КАЙТСАМ...

Үлән булсам — изәрләр,
Агач булсам — кисәрләр.
Җиләк булсам — өзәрләр,
Дәрья булсам — йөзәрләр.

Кайсы булып кайтыйм җиргә, —
Булыпмы болыт кына?
Явармын яңгыр булып,
Агармын дәрья тулып.

Агач тамырлары буйлап
Үрләрмен җимешләргә.
Тагын мине ашарлар,
Тагы туфрак ясарлар.

Әгәр тау булып кайтсам,
Туктаусыз казынырлар.
Алтын-көмеш табарлар,
Тагы да азынырлар...

Урманда булсам киек,
Елгада булсам балык?
Яшәрмен мин ут йотып,
Ашарлар диеп тотып.

Ни булып кайтыйм җиргә?
Туфрак булып ятыйммы?
Гөл тамырларына иңеп,
Чәчәк булып атыйммы?

Тагы бер кат сулырмын,
Тик бәхетле булырмын.

## БУТАЛЫШ

Дөнья ыгы–зыгы килә,
Сәхнәләрдә шоу гына.
Урамнарда тракторлар,
Ак карлардан тау гына.

Сәясмәннәр берөзлексез
Үз–үзләрен сайлауда.
Бизнесменнарның сәмәнен
Кесәләргә җайлауда.

Сукбай эт, сукбай мәчеләр,
Хуҗалары да шундый.
Яшәргә тырышучылар
Җир казый, тиен саный.

Яшәү мәгънәсен югалтып,
Элмәкләргә керәләр.
«Бездә халык рәхәт яши», —
Дип сөйлиләр түрәләр.

Зәңгәр экран, радиодан
Җыр — үткәнне сагыну,
Хыялында гына исән
Нигезенә табыну.

Бар да үтә, бар да китә,
Яшәп калырга, диләр.
Дөньядан алырга булган
Барсын алырга, диләр.

Ала, ала, ала, ала, —
Күмеләләр алтынга.
«Җитте!» — диюгә, алтыны
Әверелә ялкынга.

Тереләй тәмуг утында
Яна адәм баласы.
Уйлый һаман бу дөньядан
Калды, диеп, аласы.

Дөнья ыгы-зыгысында
Сулар болганган чакта,
Күренми агы карада,
Кара күренми акта.

* * *

Җир тудырган һәрбер нәрсә
Тамырлы...
Тамырсыз кешене тарих
Танырмы?

## II

*...Туган җирнең тузан исе тәмле,*
*Болытлары — кояш, ае — ахак.*
*Тик туган җир башка булыр иде,*
*Шулай сагынучы без булмасак...*

## БЕЗНЕҢ АВЫЛ

Сагышларым минем сары диңгез,
Ярларымда чак-чак тотып торам.
Таң тудымы — туган яктан җилләр,
Аларны да: «Кайтыгыз!» — дип борам.

Җил ватансыз, диләр, шулай микән?
Безнең яктан искән җилләрдә бит
Алмантайның җир җиләге исе,
Безнең ипи исе өйләрдән тик...

Безнең якның җиле кагылганда,
Казан каеннары ни пышылдый?
Арча, Өнсә, Күн авылы түгел,
Безнең авыл көе бит шушындый.

Безгә килгән давыл да киталмый, —
Һәрбер җанда давыл оясы бар.
Бу дөньяда «Безнең авыл» дигән
Мәңгелеккә һәйкәл куясы бар.

## БАРАСЫМ БАР...

*Әнкәйгә*

Март аеның дымык көне.
Түбәләрдә кар әле.
Моңсу гына карап әйттең:
«Сөйләр сүзләр бар әле...»

Күзләреңнән моң түгелде:
«Аһ, — дидең, — барасым бар...
Балам, җирнең минем белән
Ямыйсы ярасы бар...»

Март аеның дымык көнен
Төн манды кап-карага.
Синдәйләрне саладыр җир
Төзәлмәслек ярага.

Әнкәй, минем дә яныңа,
Беләм лә, барасым бар...
Җирнең минсез каплап булмас
Бик авыр ярасы бар...

## БЕЗ БУЛМАСАК...

Туган җирдән еракларда чакта
Күтәрелеп карыйм мин күкләргә.
Бәлки, минем мондый гадәтләрем
Сәер күренәдер бик күпләргә.

Әмма гади күк тә үзгә кебек,
Еламыйча чак-чак түзә кебек.
Күперелеп тора болытлар,
Әллә ничек кенә боеклар...

Туган җирдә алар шундый горур,
Йә арыслан, йә юлбарыс булыр, —
Өерелерләр Уралтау булып,
Ургып аккан ярсу шау булып.

Ялтыр-йолтыр яшен камчылары
Болыт кыяларны кискәләсә,
Карурмандай кара болытларны
Йолыккалап җилләр искәләсә,
Рәхәтләнеп җылы яңгыр кояр,
Күз ачкысыз буран котырыр.
Бар дөньясы туктап тынып торыр, —
Туган җирдә күкләр, һай, горур!

Туган җирдән еракларда чакта
Күтәрелеп күккә карасагыз,
Минем хәлләремне аңларсыз сез,
Җирсү дигән хәлгә тарысагыз.

...Туган җирнең тузан исе тәмле,
Болытлары — кояш, ае — ахак.
Тик туган җир башка булыр иде,
Шулай сагынучы без булмасак...

## ЯҢАВЫЛДА ТУЫП ҮСКӘН БЕЗ

*Сажидә Сөләйманова истәлегенә*

Кай җирләрдә туып үскән, диләр,
Нинди җир ул, диләр, Яңавыл?
Яңамы ул, әллә ян авылмы? —
Шигырь булып җанда яна ул!

Һәр адымы белән яңа ул!

Галим-голәмәләр, баш ватмагыз,
Ян диеп тә, яңа диеп тә.
Җаныбызны яшереп яшәдек без,
Моңга салып, янып, көеп тә.

Ул өндәде безне биеккә!

Яңа авыл түгел, ян авыл да,
Җан авыл ул, дуслар, җан авыл!
Туып үсү түгел, бер күрсәң дә,
Мәңгелеккә җанда кала ул!

Аксакал ул, сабый бала ул!

Инде бүген килеп сер чишәбез:
Җан авылда туып үскән без,
Саҗидәләр, Нәҗибәләр булып,
Шигырь дөньясына күчкәнбез.

Моң касәсен чумырып эчкән без!

Ишмораты, Гайнан Әмирие,
Нуриханы, Илдар Юзие! —
Җан авылы булган кешеләргә
Шәһре Казан һәрчак үз өе.

Яңавылда аның үз көе!

Һәр татарга кадерледер Казан,
Дошман гына аны алганмы?!
Үз баласы итеп каршылый ул
Җан авылдан иңгән җаннарны!

## ХӘЛЕМ ШУНДЫЙ...

Туган яктан аерылган чакта,
Өзелде җан кылым.
Күңелем кебек нечкәрде дә шулчак
Өзелеп калды юлым.

Яшь елгасы озата килде мине
Олуг Казаныма.
Моңлы азан иңде, шөкер әле,
Бу үксез җаныма.

Туган җирдәй якын инде Казан, —
Моңлы, манаралы.
Шул моңнарда җаным тибрәтергә
Милләтем бар әле.

Манаралар торып бассалар да,
Җаннар шуышалар...
«Аягөсте басма, иел...» — диеп
Ысылдап торалар.

Казанымнан чыгып китә калсам,
Тагы өзелер бер кыл.
Аягүрә басып каршы торыр,
Хәлем аңлап, Идел.

Уралымнан, Иделемнән китеп,
Тагы кая барыйм?!
Хәлем шундый: ташлап чыккан кебек
Иделкәем ярын...

* * *

Калганга да, киткәнгә дә авыр, —
Һәммәбезне тотып тора тамыр.
Шул тамырның сутын алсак кына,
Туган җире үз баласын таныр.

## КЫР КАЗЛАРЫ НИ ДИП КЫЧКЫРА?

Кыр казлары!
Казан өсләреннән
Очтыгызмы әле, күрмәдем?
Сагышлардан сынар чаклар булды,
Мин әлегә серләр бирмәдем.

«Сагышларың
Алып китә-ә-әм!» — диеп
Дәшкәнегез килеп җитмәде.
Сары җилләр исте, минем генә
Сагышларым алып китмәде.

Кыр казлары!
Мин таныдым сезне,
Яңаулдан күтәрелгәнсез.
Сез бит анда Буә суларында,
Бәдрәшбашта йөзеп йөргәнсез...

Кыр казлары!
Мин ишеттем сезне,
Кычкырдыгыз: «Кисәк-Каен! — дип, —
Сагышланма, анда дөнья имин,
Күреп очтык алтын аен», — дип...

---

Буә, Бәдрәшбаш — Башкортстандагы елга исемнәре.

* * *

Авылыннан китсә дә кеше,
Кавеменнән китмәсен.
Кавеменнән киткән кеше
Бәхет өмет итмәсен.

## ЕРАКТА – ЙӨРӘКТӘ

Мәрхәбә әби хат алган,
...еракта улы.
Күрше кызы укып бирде
хатны бу юлы.
«Дорогая моя мама!»
дигән үзенә.
Әллә нинди авыр яшьләр
тулды күзенә.

Үскән чакта «Әнкәем!» дип
әйтә иде бит.
Көнен китсә дә, сагынып
кайта иде бит.

Мәрхәбә әби хат алган,
...улы еракта.
Әллә нинди шомлы уйлар
хәзер йөрәктә.

«Әнкәй» дигән гап-гади сүз
җитми шул аңа.
Ят сүзләрдән анын бары
сагышы яна.

Нигә «Нихәл, әнкәй!» диеп
башламый хатын?
Нигә алай төчеләнү,
белмиме затын?
«Әнкәем» дигән бер сүзгә
һәммәсе сыя.

«Дорогая моя мама»
жанкаен кыя.
Әле күрше-күләнгә дә
сәлам юлламый, —
Әллә авылдашларын ул
бер дә уйламый?
«С приветом, — диеп куйган, —
твой сын Назми».
Әби тагы хат яздырды,
йөрәге түзми:
«Үз уеңны үз телеңдә
әйтә алмагач,
Әнкәң янына бер көнгә
кайта алмагач,
Ул кайсылай «дорогая»
буладыр инде.
Киткәнеңә егерме ел
туладыр инде...
Син киткән елны утырткан
затлы алмагач
Тәрәзәгә авып төште,
чара калмагач».

Җавап алалмады әби
язган хатына,
Җаны әрнеп, китеп барды
Хода катына.

## ҖИР ЙӨРӘГЕ

Әгәр җирдә чын сихерче
Бар икән, ул — туган җир.
Туган җирен оныткангa
Табылмас хөрмәт–кадер.

Изге анам, туган җирем,
Туган телем, туган ил —
Кешенең рухи дүрт саны.
Исән булса, бәхет шул.

Җырларым сезсез бер моңсыз,
Күңелем нурсыз, өнсез.
Дөнья читләреннән кайтам
Ишетергә тик бер сүз.

Туган җирдән читтә үткән
Көннәрем әллә азмы?
Җир йөрәге туган җирдә,
Кош та эзли шул назны.

## ӘГӘР ШУЛАЙ БУЛСА

Ут булсаң, сүндерерләр,
Су булсаң, сеңдерерләр.
Таш булсаң, йә атарлар,
Җиргә салып таптарлар.

Сүнмә, сеңмә, атылма,
Чит табаннан тапталма!
Тап төшермә затыңа!
Хөкем юк ул үз җиренә
Туфрак булып ятканга!

## ИКЕЛӘНҮ

Мин кайттым. Мине өемдә
Беркем дә көтеп тормаган.
Тынып калган сәгать теле,
Беркем ачкычын бормаган.

Мин калдырган килеш тора
Тустаганда сөтсез чәем.
Хушлашырга базмый шаулый
Инде үтеп киткән җәем.

Ачык калган тәрәзәмнән
Сары яфрак очып кергән.
Әйтерсең лә минсез өйдә
Минем гомер көзем йөргән.

Җәйдән калган тузаннарны
Сөртергәме, сөртмәскәме?..
Гомеремнең көзе шакый,
Кертергәме, кертмәскәме?..

## ТӨНГЕ ВАСЫЯТЬ

*Энем Әнгамга*

...Әгәр сиңа шалтыратсам
Төнге сәгать уникедә,
Аһ, ачуың килер иде.
Ачуланыр идем мин дә.

Әмма «Нигә уятасың
Син йокымнан?» диеп түгел, —
Синең миңа дәшүеңне
Көптән көтә иде күңел.

Шул гомерләр хәлгә керми,
Ай кадәрле айны күрми,
Ничекләр яшисеңдер шул? —
Күңелемә сагыш үрли.

Яфракларны уятасы
Бар дип чакырдым җилне.
Мондый йокы буламыни? —
Гафләт баскан бар илне...

Суверен йолдызлар гына
Аңлап күз кыса миңа.
Әгәр төнлә шалтыратсам,
Ни диярмен соң, сиңа?

Ник кош түгел, очалмыйм дип
Елап алырмын, бәлки,
Йолдызлар сәлам юллый дип
Алдашырмындыр яки.

Бәлки, айны гаепләрмен, —
Өйләнми йөри һаман.
Имеш, моңсудан да моңсу, —
Шул кирәк аңа, таман.

Ә күккә гомерендә бер
Күз күтәреп бакмаган,
Төнге сулар белән бергә
Кушылыплар акмаган.

Кемсәләрне тиргәмәм мин,
Бары тик кызганырмын.
Йолдызлар дәшеп торалар —
Сәфәргә кузгалырмын.

Китеп барсам, сагынсагыз,
Эзләгез мине күктән, —
Кол санына сыймаган җан
Йолдыз иләндә күптән.

## ЧАЛГЫ ЧЫҢЫ

*Мәшһүр җырчыбыз*
*Гөлсем Сөләйманова истәлегенә*

Мең гасырда түгел, бер гасырда
Андыйм дисәң җанын,
Искә алып кара ул халыкның
Җырчылары барын.

### I

Печән өсте. Печән башка чөелә,
Күккә — чая сүзләр...
Учак уты сыман ялтырыйлар
Елтыр, чая күзләр.

Баш өстенә менеп баса кояш,
Аш вакыты җитә...
Көтмәгәндә гүя сихри набат
Кояш кылын чиртә.

Төптән күтәрелгән асыл моңнан
Шашып куя йөрәк...
Патефон да килгән... завклуб та
Асыл егет, димәк.

### II

Аш чүмече тоткан әнкәй тынган,
Әткәй... тынган чүкеч...
Гөлсем апа җырлый... болын тынган, —
Кодрәтле бу көч.

Үкенечләр өскә калкып чыга —
Үткән, беткән, бик соң!
Киләчәккә дәшеп аваз килә,
Ачылып килә гамь, моң.

Әйтерсең лә шушы моңга килеп
Кушыла агымсулар.
Бу авазга кемнәр җиңел сулар,
Кемнәр авыр сулар.

### III

Печән өсте. Үткән гасыр бара —
Гөлсем апа чоры...
Машиналар чорын таптый Хәтер —
Кайта чалгы чыңы.

## ӘНКӘМ ӨНЕ

Үз-үземә хөррият мин,
Үз-үземә хуҗа дип,
Ялгыз утырам өемдә,
Сагыш күлмәгем киеп.

Табигать гел хәрәкәттә:
Җил исә, ява яңгыр...
Күбәләкләр гөл имәләр,
Аһ, шифалары бардыр.

Ә минем кулымда каләм, —
Һаман өемдә калам...
Өн ишетәм, дәшә әнкәм:
«Сәхраларга чык, балам».

Бары шул өн мине тартып
Чыгара урамнарга.
Сәер халәтләрдә калып,
Адашам бураннарда.

Коеп яуган яңгырларда
Йөримен сулар ерып...
Карурманнар кочагында
Каламын төннәр кунып.

Шул караңгылык эченнән
Гүя әллә кем килә,
Әллә кеменнән алда ук
Бер гаҗәеп өн килә:

«...Үз-үзеңә кол була бел,
Үз-үзеңә хуҗа син.
Татыганга бу дөньяның
Сәгадәтен, нужасын.

Шушы халәтеңнән китми,
Яза-яза җырыңны —
Илтеп ялгарга тиешсең
Киләчәккә чорыңны!»

Һәм шушы өн тагы мине
Каләмгә бәйләп куя.
Җаныма шагыйрьлек дигән
Тылсымлы мөһер уя.

Җилләр артыннан йөгерәм,
Юлыгам ташкыннарга...
Канатсыз килеш кояшка
Җитәргә ашкынганга.

Һәм тагын да әнкәм өне:
«Кил, балам, сагындым ла.
Чү! Балам, чү, бик ашыкма,
Тигездә абындың ла».

...Бәлки, яшәү рәвешемдер:
Табынып... абынып...
Үз-үзеңә хуҗа да бул,
Бул хуҗаның колы да.

# КЫР КАЗЛАРЫ АРТЫННАН

*Илдар ага Юзеевка*

Иделгә коя Яңаул, —
Казан нык тоя иде.
Әйе, Буй елгасы буйлап
Иделгә коя иде...

Китте Ишморат, Саҗидә,
Китте Нуриханы да.
Атмый калыр дигән идем
Инде бүген таңы да...

Юзиләрсез калган Казан,
Яңаулларсыз нишләр?
Яңаулдашларны эзләп
Каңгырдым таңда, исәр.

Илдә кадерсез булуның
Ни икәнен беләбез...
Китәр кошлар булып кына
Тулы гасыр бөләбез.

Без киткәч, туза оялар,
Туздыралар шул аны...
Оялы агачлар елап
Көтеп торалар тагы.

Бу язда ничек кайтырмын? —
Юлдашларсыз калдым ла.
Инде тагы бер моңлы кош
Кайталмас Яңаулга.

Күңелнең нечкә кыллары
Киерелеп тартылган, —
Илдар абый китеп барды
Кыр казлары артыннан.

III

*Ул кайткан –*
*Халык күңеле*
*Күтәп алган ул назны!*
*Ул китмәде,*
*Китмәячәк,*
*Кайтарачак милләтенә*
*Кояшлы азат язны!*

# ТУКАЙГА ДӘШҮ

Нихәл, Тукай?
Җанда нинди гамьнәр?
Таш сыныңны сыгып аумыйсыңмы?
Җан җылысы эзләп сиңа килдем,
Эшләр кая бара, аңлыйсыңмы?

Дөнья кызу!
Җан әрнүдән тора.
Таш булсаң да, елый алмыйсыңмы?
Ташлар булып ташлар ыңгыраша,
Дөнья кая бара, аңлыйсыңмы?

Анда ташлар,
Монда башлар ава.
Коллык богауларын таныйсыңмы?
Җан кадәрле җанны кол итәргә
Инквизиция бара, аңлыйсыңмы?

Анда таулар,
Монда олуг Идел
Аягүрә баскан, тоясыңмы?
Салым түләгәч, тик яктыртырга
Фәрман чыгарылган Кояшыңа.

Агач төбе,
Ат аунаган төге —
Барысына да салым салынган бит!
Милләттән җан, мөлкәте һәм аңы,
Җирнең мае сыгып алынган бит...

Нихәл, Тукай?
Монда шундый хәлләр.
Таш сыныңа килдем җылы эзләп.
Җаннарда таш, таштай ауный башлар,
Киселәләр алар йөзләп-йөзләп!

Нихәл, нихәл,
Тукай атлы әрнү?
Мин — Нәҗибә атлы җан ярасы...
Тау ватканчы әле ул тузанга
Кирәк иде таута табынасы.

Нихәл, тарих
Олут Тукай атлы?
Монда тузан сулышларны каплый.
Җаннарда да хәзер тау ярасы,
Тауларда да икән җан ярасы,
Бер Аллага калды ялварасы!

Дәш, Таш Тукай!
Җанда нинди хәлләр?
Таш сыныңны орып аумыйсыңмы?
Җаннар хәзер таштай катып калды,
Таш Тукаем, мине аңлыйсыңмы?
Таш Тукаем, безне аңлыйсыңмы?
Таш булсаң да, әллә аңлыйсыңмы?
Күз яшьләрен безнең таныйсыңмы?!

## И–И, ТУКАЙҖАН!..

И–и, туганнар!
Каршыгызга чыктым,
Басып торам.
Җаным тагын
Сезнең җанга орам.
Ни хәл генә итим,
Нишлим лә?
Тагын иренемне
Тешлим лә...

Хак дөресен
Әгәр әйтә калсам,
Җан илемнән мине
Куарлармы?
Кумасалар,
Бәлки, кумаслар да...
Әмма мыштым гына
Буарлармы?!

И–и, Тукайҗан!
Мин каршыңа чыктым.
Басып торам.
Җаным тагы
Моң сыныңа орам.
Сине сөйгән халкың
Бүген дә
Басып тора
Ишек төбендә...

Бәй–й–й...
Син үзең дә
Әллә кайда түгел,
Басып торасың ич
Бүген дә
Зу–у–ур мәйданның
Уртасында түгел,
Халык йөрмәс
Ишек төбендә.

Моннан үтеп-сүтеп
Йөрүчеләр
Борылып та сиңа
Карамыйлар.
Мәйданнарда
Анда башка кавем,
Сине тотып тора
«Ярамыйлар»...

Бәй-й-й...
Бүген дә
«Заман — көчленеке!»
Халык уе
Бары уенчыкмы?
Синең исемең белән
Уйнаргамы? —
Лауреат дигән
Уен чыкты...

Уен түгел,
Халык уе иде,
Күрәсеңме,
Нинди заман килде?
Дәүләтсез һәм
Телсез калган халык
Үзе күптән
Кәмит уйный инде.

Тик белсеннәр,
Бу янавым түгел,
Кәмит бетте...
Кәмит la finist!
Туры Тукай булсам,
Әйтер идем...
Әйтә алмыйм...
Әйтәм зашибись:
Халык уйларын да
Уен итеп
Кидергәнгә чылбыр уйларга,
Якын килә алмаячак тиздән
Түрә-мүрә Сабантуйларга...

Бу янавым түгел,
Тик әлегә
Бу — ямавым
Җаным ярасын...
Исләренә
Бер төшерим дидем,
Уен беткәч,
Хәтта түрәнең дә
Безнең белән
Бергә барасын!
Башка юл юк —
Бармый карасын!..

## ТУГАН ТЕЛ — НАМАЗ

Әбием минем, әбием минем!
Ул киеп йөри борынгы кием.
Аның күлмәге алсу ефәктән,
Вак-вак бөрмәләр матур итәктә.

Йомшак камзулы чия төсендә,
Әбием көн дә намаз өстендә.
Чәчләре кебек ап-ак яулыгы,
Аллага шөкер әле саулыгы.

Икәү көн саен җырлыйбыз бер җыр, —
«Туган тел» җырын язган зур шагыйрь.
Аның исеме — Габдулла Тукай,
Бу хакта хәтта белә, ди, Ходай.

Ачыла күзем, чәчелә йокым, —
Мин намазлыкта «Туган тел» укыйм.

## ЕГЫЛМАСЫН, ЮГАЛМАСЫН ДИСӘҢ...

Юллар өзелгән чак була
Җәяүлегә, атлыга.
Еллар өзелгән чак була
Туры сүзле, хаклыга.

Телдән телгә генә күчеп
Яңгырый ул чак чын сүз.
Өзелә үзәк, киселә бәгырь –
Дәшә генә күрмә, түз!

Моңнар өзелеп калмасын,
Моңнар җаннан агыла.
Туган телнең тамырына
Балта-пычак кагыла.
Үзең белән бу дөньяга
Бергә туган телеңне,
Туфрагыңа ялантәпи
Баскан газиз җиреңне
Үзеңнеке түгел диеп
Исбат итәләр икән,
Ул бәндә үз иманыннан
Әллә кайчан ук киткән.

Өзелмәсен дисәң юллар,
Өзелмәсен дисәң уйлар,
Егылмасын дисәң ирләр,
Югалмасын дисәң илләр,
Яклау кирәк туган телне,
Аклау кирәк туган телне,
Туган телдә туган җирдә
Яңгыраган изге җирне!

## ТУКАЙ КАБАТ ТУАР

Мин шатлыктан күккә ашар идем,
Очкан кошны тотып кочар идем,
Күңелләрнең садә кылларында
Бәхет көен табып уйнар идем...

Бәхет көе шундый булыр иде,
Бәхетеннән ярлар тулыр иде.
Җырлап торыр иде бар мәйдан
Һәм таң калыр иде: моң кайдан?

Мәйдан көләр иде... биер иде...
Әй очыныр иде шатлыктан!
Хәтта таш сынына Тукайның
Җан өрелер иде хаклыктан.

Мин шатлыктан әллә нишләр идем,
Һәр бөҗәкне тотып үбәр идем.
Шүрәлесе кытыклаган кеби,
Шатлыгыннан Тукай көләр иде...

Тик әлегә Тукай таш сын гына,
Юк, биеми мәйдан әлегә.
Тик җаннары һаман зынҗырда,
Мәйданнарда сирәк чын җыр да.

Ул чын булса, әйе, елый гына,
Ул чын булса, иңри, игәлә.
«Коллык богауларын өзәргә!» — дип,
Бакый җаннар фәрман биргәнгә.

Ул чын булса, җирнең үзе кебек
Ыңгыраша табан астында.
Чечен каны тама аңардан —
Иске яралары яңарган...

Ул чын булса, аның таләбе бер:
Дәүләт кирәк җирдә яшәргә!
Дәүләт кирәк, дәүләт теле кирәк
Чын шатлыклар белән яшьнәргә!

Ә әлегә күккә ашар өчен
Канат бәйле, богау — аякта.
Богау — телдә, богау — кулларда
Һәм Чечняда әле уллар да...

Ә әлегә Тукай катып калган,
Җанында таш ничек эресен?!
Безнең хыял әгәр чынга ашса,
Җан инңәчәк аңа, күрерсең...

Менә кайчан Тукай кабат туар!
«Христос кына воскрес» димәгез.
Шагыйрь юкса ул очарга тиеш,
Кошлар гына оча димәгез!..

Без әлегә, хыялларны кочып,
Канап торган җиргә иңәбез...
Бу сүзләрдә тамчы ялган да юк,
Шагыйранә ялган димәгез...

## ИСКӘ АЛУ КӨНЕНДӘ УЙЛАНУ

Сине искә алу көне, диләр,
Истән чыккан чагың бармыни?
Нигә шулай иртә китеп бардың,
Безнең дөнья шулай тармыни?

Ташкыннарның гомере язда, беләм,
Ярларга да сыймый җырларың.
Әллә ничек кенә кысыла да
Тарая шул яры чорларның...

Тик ярларны кысып түгеп булмый
Халык моңы дигән назларны.
Кырык катламнарны үтеп чыгып,
Исемнәре кайтты азларның...

Яшеннәрне яшереп буламыни? —
Син китмәдең безнең күңелдән.
Син халкымның җаны тулып ташып,
Изге моңы булып түгелгән...

Сине бүген искә алу көне —
Шундый йола безнең халыкта.
Ничек онытсыннар, күңелләрнең
Олуг өметедәй калык та.

Синең бары җырлап бу дөньядан
Китеп барган көнең, Тукайҗан!
Чишмә — җырлап, кеше җылап туа,
Җырлап киткән үлми һичкайчан!

## ФИКЕРЛЕНЕ КҮТӘРӘ АЛСАК...

Рәсәй тәхетенә иблис менде,
Нәни тәхетләрдә — варислары.
Җимерүләрен сизмәсеннәр диеп,
Бишек җыры көйләү бар эшләре.

Җаннан чыккан җанга иңгәнлеген
Аңлап алды алар, аңладылар.
Әмма ашыгалар, тизлекләрен
Берничек тә көйли алмадылар.

Алар җыры халык моңы түгел,
Алар җыры бары такмак кына.
Сүзен язып, җырын җырлап йөри
Шуны аңламаган ахмак кына.

Ашыгулар — шайтан шөгыле шул,
Шайтан чирен кеше йоктырган.
Эш кырмыйча, бәхет табам диеп,
Шайтан сүзен тоткан оттырган.

Бүген бар да сорый кыскалыкны, —
Кыска сүз, уй, кыска итәкләр.
Кыса алсаң, ачтан үлмисең дип
Киңәш бирә миңа тинтәкләр.

Ә мин кыска түгел, кышка язам,
Ап–ак карда калсын җан эзем.
Ташкын булып ак син океаннарга,
Болыт булып күккә мен, сүзем!

Яу коеп та, ләйсән булып та яу,
Һушларына китер халкымны!
Ашыкмаска өйрәт, ныклап өйрәт, —
Тиеш җиргә салсын ялкынны!

Тәхетләрне нигә яндыралар? —
Ах, туйдырды инде җан сораулар!
Тукайларны тартып алды алар,
Бүген ифрат авыр җан асраулар.

Ә чын шагыйрь халык көен көйли,
Һәм нәкъ менә шуны иблис сөйми.
Фикерлене күккә күтәрә алсак,
Хак Аллага илче җибәрер чак.

Әйтсен халык көен көйләгәнгә
Яшьли Тукай җаны кыелганын,
Иблис менгәч Рәсәй тәхетенә,
Халык сүзе тәмам тыелганын.

Галиҗәнап сүзнең гаделлеккә
Иң зур кораллыгын танымыйлар.
Шайтан суын, наркотигын эчеп
Исергәннәр инде айнымыйлар.

Әйтсен: туплар гына сөйли хәзер,
Ә шагыйрьләр аяк астында.
Бер күз салсын әле безгә Алла
Күк капусын гына ачсын да.

# ТУКАЙЧАРАК БЕЗНЕҢ ЗАМАН

## I

Чыксам урамга,
Китә кәефем.
Урам чатлары
Тулы хәерче.

Ава да түнә
Исерек килә.
«Ис–се–рек» диеп,
Ул синнән көлә.

Кыяфәтләре,
Куй, афәт бары.
Сөйли башласа
Әле ул зарын...

## II

Чак араланып
Шушы афәттән,
Тынычлыйм диеп,
Мин өйгә кайтам.

Ишек шакыйлар,
Ишекне ачам:
Тагы хәерче, —
Кайларга качыйм?!

Сузган кулларын,
Тезгән улларын,
Алла хакына
Теләнә бары.

Бай ишекләре
Бар да бикле шул.
Бирүләре дә
Бик тә шикле шул.

## III

Бу нинди гасыр?
Нинди чор, Тукай?
Заманың миңа
Кайтты да бугай.

Койма аркылы
Бай аваз сала:
«Коймаларны сөрт,
Чир йогып кала».

Кичә мәктәптә
Мине укыткан
Мөгаллимә бит
Чыга ишектән.

Кулында чиләк,
Кулында чүпрәк.
Бу кыяфәте
Миңа читрәк.

Мөгаллимәбез
Хезмәтче икән.
Димәк, ул инде
Соң чиккә җиткән.

Урамга чыксам,
Өемә кайтсам...
Эх, җырлар идем,
Бер шатлык тапсам...

## ТУГАН ТЕЛЕМ

Телемне ачкан тәүге сүз —
Әнкәй һәм әткәй.
Ние бармы ул сүзләрнең,
Кай бала әйтми?

Җанымны ачкан тәүге сүз —
«Сине яратам!»
Әйтелгәндер инде бу сүз
Кемгә карата?

Әнкәйгә, әткәемә дә,
Әби, бабайга,
Чәч толымнарымны тартып
Киткән малайга.

Әйтелгәндер синең эзләр
Калган урамга,
Чәчләремә көмеш карлар
Салган буранга.

Әйтелгәндер Иделемә,
Туган илемә,
Синең өчен чәчәк аткан
Зәңгәр гөлемә.

Әйтелгәндер Уралыма,
Очар кошларга,
Бит очларын чеметтергән
Салкын кышларга.

Язларына, көзләренә,
Җәйләренә дә,
Туган телдә җырлап аккан
«Әй»ләренә дә.

Агыйделгә, Кариделгә,
Бүә суына,
Әкиятләрдәй җанга иңгән
Сабан туена.

Җиленә дә, давылына,
Сагышына да,
Зәңгәр күлнең керфекләре —
Камышына да.

«Яратам!» — дидем барсына
Туган телемдә —
Әткәй-әнкәй, әби-бабай,
Тукай телендә.

Туган телдә әйтелгәнгә,
Бар да ишеткән!
«Саумы, әнкәй!» — диеп керә
Балам ишектән!

## Ә ИРТӘГӘ

Галибанә яктырып, әкрен генә
ал таң атсын,
Гаскәр кеби чыршы-нарат
төпләрендә
Күккә карап, хәлләр җыеп
татар ятсын.
Сөйләшсеннәр күбәләкләр
һәм балалар.
«Әллүки»ләр, «Тәфтиләү»ләр —
җанда алар.

Тик киләчәккә аласым
килми минем
Дәүләтсез вә туган телсез
милләтемнең кимсенүен.
Юк, кушылып күзгә ачы
җилләргә лә
Чәчелмәсен милләт чит-ят
җирләргә дә.

Аһ, тарихта калса иде
ачы җилләр,
Теләктәшлек итсә иде бер-берсенә
төрки илләр.
Туган җирем үземнеке
дисәм иде,
Тик халкыма гына башым
исәм иде.

Су аналы, Шүрәлеле
урманнар да,
Албастылы, җен-пәриле
аланнар да —
Һәммәсе дә кирәк миңа
киләчәккә.
Мин — Шүрәле, бәхетемнән
көлгән чакта.

Тик кирәкми бүгенгедәй
тиен санап,
Җан асырап шөкер иткән
мәэюс күзләр.
Нишлисең, дип, гаҗизлектән
телен йотып,
Күз яшьләрен җанга бикләп
әйткән сүзләр...

Юк, кирәкми, без дәүләтсез
бүген дә дип,
Чарасыздан күз яшьләре
түгүләр тик.
Насарыйдан начар түгел
юкса татар,
Аһ, кайчан соң галибанә
яктырып ла
Милләтемнең, дәүләтемнең
таңы атар?

Әй, милләтем моң чишмәсе —
Тукай җаным!
Милләтеңне зур итәргә
бирдең җаның.
Миңа кирәк хыялларың
чынга ашу,
Үтеп китте, үтте гасыр —
гел моң-ташу.

Вакыт шундый, таулардан да
дала ясый.
Ә дулкыннар текә ярын
нигә ашый?
Гасырларча кысып торган
зынҗырлары,
Җанны кисеп, кешеләрдән
янус ясый.

Икейөзле затлар инде
иблис була.
Бар милләтең иблисләргә
әверелгәнче,
Соңгы чиктә текә ярга
бәрелгәнче, —
Уйла татар, бүген уйла,
Ә иртәгә,
Ә төштән соң инде соң була.
Бүген уйла! Бүген уйла!

# УЛ КАЙТТЫ МӘҢГЕЛЕККӘ

*Габдулла Тукайның Казанга кайтуына*
*100 ел тулу уңаеннан*

Ул кайтты —
Вакыт бизмәне
Үлчәгән — узган гасыр.
Ул китмәде,
Китмәячәк,
Киләсе гасырларның да
Милләт капкасын ачар!

Ул кайткан —
Халык күңеле
Күтеп алган ул назны!
Ул китмәде,
Китмәячәк,
Кайтарачак милләтенә
Кояшлы азат язны!

Ул кайткан
Халык җанына!
Ә җан — мәңге,
Мәңгелек!
Мәңгелекнең ни икәнен
Аңласын
Милләт элек.
Татар — бар!
Булган! Булачак!
Җирдә — Тукай, күктә — ай!
Барны юк «ясаучылар»га
Ышанырга я-ра-мый!!!

## ҮЗГӘРМӘГӘН ӘЛЕ БЕЗНЕҢ ҖЫР

*(Тукайга кушылып)*

Аһ, Дума, Дума, Дума!
Эшләгән эшең бума?

*Г.Тукай*

Ник бик тиз җебеп төштең син,
Ник ирек дауламадың?
Аһ син, Дума, Дума, Дума,
Үз юлың табалмадың?

Ник алай тиз бирештең син
Ялган вәгъдә, буш сүзгә?
Ә бит милләт, аһ, ничекләр
Ышанып торды сезгә...

Ник безне кызганмадың син? —
Коллыктан коткармадың?
Бугазына басалмадың
Бугаздан тотканнарның?

Ник баш бөктең залимнәргә,
Ник сүзләрен тыңладың?
Ник талаттың милләтеңне,
Талаучыны тыймадың?

Бирәм диден, вәгъдә бирдең,
Күрсәт, ирек кайда ул?
Милләткә дигән бар байлык
Ничә генә байда ул?

Самый важный генерал да
Катыктан акча алды.
Ә милләт таланган килеш
«Ни с чем» утырып калды.

Әйдә, дуслар, бер тибрәник,
Акны Тәңре яклар бит.
Караны беркөн каралтып,
Акны беркөн аклар бит.

Әй, Тукайҗан, гасыр элек
Сине яшәткән өмид
Бездә дә сүнеп бетмәде,
Бетмәде әле сүнеп.

Тик куркыныч, коллыгына
Милләтем бара күнеп...

Урманнарда телсез күке,
Сандугачы да чыпчык...
Чишмәләр сазга әйләнгән, —
Милләтем, батма, чык, чык!

Җандагы өмет утын да
Өреп сүндермәкчеләр.
Колның телсезлегенә дә
Инде күндермәкчеләр.

Әй, Татарстан Думасы!
Син телсез, бахыр, җансыз.
Җаныңны шайтанга саткач,
Милләтең калды сансыз.

Әмма җанын сатмады ул,
Дәшалмый гына тора.
Милләткә ни кирәклеген
Кабат Тукайдан сора:

Үз дәүләте, Туган теле,
Туган җире, Болгары —
Милләтне яшәтер өчен
Шулар кирәк нибары!

Шулар кирәк нибары!
Шуны эшли алмаганнар
Милләтнең башына басып
Үрләмәсен югары!

# ТАТАР ТАГЫН ЙОКЛЫЙ

Менсә ялган тәхеткә,
Юл ябыла бәхеткә.

Эндәшәсем килә әллә кемгә,
Уятасым килә йокысыннан.
Таң атканда йокысыннан арынып
Дәшәр кешем инде юк та сыман.

Беләм, күбесенең кан басымы.
Яшьләр таңда гына кайтып яткан.
Кем бар уйны уйга ялгый алыр,
Аера алыр караларны актан?

Әйе, шундый көнгә калдык инде:
Безгә кара булган кемгәдер — ак.
Мең елларча вөҗдансызлык булган,
Бинахак саналган да аңа хак...

Тәхеткә үк менде инде ялган.
Канун көче — сыра күбеге.
Дулкын тәэсирендә сайланганнар —
Болганчык су өсте чүбеге.

«Без тарихта эзле» дия-дия,
Җуя барабыз бит эзебезне...
Болай барса, тарих танымас та
Безнең төрки дигән йөзебезне.

Таң вакыты. Татар тагын йоклый.
Рух сагында бары шагыйрь багы.
Кабатласа иде олы тарих
Дәүләт башында да шагыйрь чагын!

## БАРЛАУ

Ялгыз мизгелләрем мине
Тукайга алып килә.
Каршы ала мине шагыйрь,
Ерактан көлә–көлә.

Таш сынын бөгеп сәламли,
Сузалмый кулын гына.
«Рәхмәт, — ди, — тагы килгәнсең,
Үзгәртмә юлың гына.

Мин дә ялгыз ел буена
Көтеп торам гавамны.
Килсәләр, барлар идем, дип,
Туган телле дәвамны...»

## IV

*Мин сине дә укып чыктым,*
*Авыр китап булдың син.*
*Җаныңа гасырлар сыйган*
*Дәвер–китап булдың син.*

## ИХ, СИН БУЛСАҢ ЯНДА...

Их, син булсаң янда,
Их, син булсаң...
Дөнья башка булыр иде бит.
Күңелләргә әллә нинди дәртләр,
Җанга гамьнәр тулыр иде бит...

Көзге яңгыр салкын булмас иде,
Чатыр алмас идем кулыма.
Чыланасың, юләр, нишлисең, дип
Йөгереп чыгар идең юлыма...

Ә мин чәчләремә яңгыр төяп,
Алтын сукмакларны нур итеп,
Көзнең яңгырлары шыбырдавын,
Яфракларның зарын җыр итеп,
Бер әйләнеп кайтыр идем әле,
Сискәндереп көзге урманны.
Хәтереңдәме, ничек кызык иттек
Ул чак... ап-ак кышкы буранны...

Чыдый алмый буран өйгә керде,
Тузган чәчләремә уралып.
Шушы хакта нигә уйланамдыр,
Төн урталарында уянып...

«Чык» та «чык» дип, тәрәз чиртә яңгыр,
Шашып-шашып әйди җилләре:
«Алтын түшим йөрер юлларыңа,
Өзеп бирәм соңгы гөлләрне...»

Их, син булсаң,
Их, син булсаң янда...
Мин җилләрдән битәр шашар идем,
Яңгыр җепләренә тотынып кына,
Болытларга кадәр ашар идем...

Син булмагач,
Җанда яңгыр гына...
Яфракларны җилләр өзгәли.
Минем кебек бәргәләнә яфрак,
Кәүсәсеннән җил дә өзәлми...

Их, син булсаң янда...

## ЯЛГЫШМЫЙЧА ЯЛГЫШТЫК

Таңга кояш буласым,
Төнгә айдай туласым
Килде. Миннән көлделәр:
«Кеше бул син!» — диделәр.

Былбыл буласым килде,
Талга кунасым килде.
Күп чакларда бары синең
Янда буласым килде.

Былбыл да булалмадым,
Талларга куналмадым.
Хәтта синең өчен генә
Бердәнбер булалмадым.

Уйлап карадым: кайчан соң,
Без кай җирдә ялгыштык?
Кайсы мәлдә, әллә инде
Ялгышмауда ялгышлык?

Инде хәзер, еллар үткәч,
Үкенүдән ни файда...
Акылларны җиңә алыр
Ярсу хисләрем кайда?

## ЧАРАЛАРЫ ЮК ИДЕ

Чәчәкле яз иде ул чак,
Елгалар таша иде.
Язның садә бөреләре
Күзләрен ача иде.

Карашларың үбеп алды,
Керфекләрең ук иде.
Йөрәгемне сиңа бирми
Калыр чарам юк иде.

Йөрәгем төште ташкынга,
Йөзеп кереп ал инде.
Язмышларым түгелмәслек
Ярым булып кал инде.

Ташкыннары шаулап узды,
Калды мәхәббәт кенә.
Синең күз карашларыңнан
Алдым җәрәхәт кенә.

Ярларыңнан түкте язмыш,
Түгелгәнсең ич син дә.
Күкрәгемдә синең йөрәк,
Минем йөрәгем синдә.

Карашларың өтеп алды,
Керфекләрең ук иде.
Йөрәгемне кайтарырдай
Чараларым юк иде...

* * *

Кагылма җанга, кагылсаң,
Кузгалып китәр ташкын.
Яшьлегемдә, абайламый,
Мин ярларымнан таштым.

Җаным — язгы тал бәбкәсе, —
Мамык — тиз кабынучан...
Яз көне шашкын йөрәкләр
Була еш абынучан...

Мин мәхәббәткә абындым,
Ә ул күкләргә чөйде.
Канатлар, кояшка тиеп,
Кырык җиреннән көйде...

Кагыл, әгәр дә кояшка
Чөярлек булса көчең,
Мин кабат көяргә әзер
Шундый мәхәббәт өчен...

* * *

Син мине кол иттең,
Син мине тол иттең,
Син мине җыр иттең,
Хыялдан чын иттең,
Мәхәббәт!!!

## ӘГӘР БЕЛСӘ...

Минем хәлне балык күрсә,
Күлен миңа бирер иде.
Ул аңласа, суга керми,
Утка үзе керер иде.

Минем хәлне кошлар күрсә,
Канатларын ташлар иде.
Миңа биреп канатларын,
Җәяү йөри башлар иде...

Минем хәлне тик син генә
Күреп тордың — җаның сукыр.
Тик син салган яраларны
Бер тотлыкмый сукыр укыр...

Балык, кошлар минем хәлне,
Минем хәлне белми әле.
Аңлар иде Мәҗнүн үзе,
Синнән алай булмый әле,
Синнән... булмый...

## ИШЕТӘСЕҢМЕ?..

Була микән шулкадәрле ярату? —
Карашыңнан күңелемдә таң ату!

Мәхәббәтме шулкадәрле зурлыкта? —
Тузандай тик кечерәя тау кадәрле
хурлык та!

Зурдан да зур була ала мәхәббәт,
Зардан да җыр сыга ала мәхәббәт!

## КӨЧЛЕРӘК...

Сагынам,
Яшерә алмыйм,
Юләр йөрәк ярата.
Ни дип әйтергә дә белмим
Шул сөюгә карата.

Яратам,
Исәр йөрәгем
Ярый әле гел биктә.
Хода белеп тота икән
Шул шашкынны читлектә.

Баш тартам
Шул мәхәббәттән,
Мин йөрәктән көчлерәк...
Читлектән дә чыгалмаган
Йөрәкне йөрим сөйрәп...

## НИК КАГЫЛДЫҢ?

Үзгәрдеме әллә синең белән
Көне йә төннәре?
Агачларда бөре урынына
Сагыш төеннәре.

Ерак язда бөре килеш калган
Хисләр иде миндә.
Сары көзең, ак бураның белән
Ник кагылдың син, ә?

Мин чын сөю көтеп көзгә җиттем —
Яфрак яра идем...
Сөю үзе килеп кагылганчы
Барыбер бара идем.

Көзен яфрак яра идем әле,
Барысына үч итеп.
Чәчәк булып тамар иде карга
Йөрәгем, тып итеп.

Үзгәрдеме дөнья сине тапкач?
Үзгәрдеме һава?
Көзен — сары яфрак, ә кышларын
Һаман ак кар ява.

Үзгәрде бу дөнья көзгә кергәч,
Сөю көзе белән күзгә кергәч...

## ТӨШЛӘР ЭЗЛӘП КАЙТАМ

Төш иде бу: мине башка
Берәү кочмакчы булды;
Мине кочып, ләззәтләнеп,
Күккә очмакчы булды.
Әллә инде шул мизгелдә
Мин дә дәртләнеп киттем,
Аһ, оят, тик, дулкынланып,
Аның кочуын көттем.
Дәрт учагы яктырттымы —
Анык күрдем йөземне.
Талпындым, әйтмәкче булып
Карышулы сүземне.
Шайтан көзгесендә күрдем
Дөрләп кабынган йөзем.
Кая сүзләр — инде аны
Мин башлап кочтым үзем.
Әмма гөнаһ кылынмады —
Күңел капкасы бикле.
Син кайттың да ачып кердең
Ишеккә салган бикне.
Төш иде бу. Тик барыбер
Син коткардың афәттән...

Көткәнсеңдер, күзләреңне
Алмый алсу шәфәкъттан.
Җаныңнан да якынрак
Килә алмыйм бит инде.
Бу төш кенә, өннәремә
Кайтып кералмыйм инде.
Анда син юк! Нигә өннәр?
Кайтасым килми өнгә.
Төшләр генә эзләп кайтам
Мин синсез буп-буш өйгә...

## СИННӘН МИҢА...

Синнән миңа шулкадәрле аз кирәк —
Бер җылы сүз генә.
Синнән миңа шулкадәр күп кирәк —
Син миңа түз генә.

Шулкадәрле синнән аз сорыйм бит —
Сөеп кенә кагыл.
Синнән миңа шулкадәр күп кирәк —
Илһам булып агыл.

Бик аз гына сорыйм, бик аз гына —
Бары тик наз гына.
Күп тә сорамыйм бит сөюеңнән —
Акылдан яз гына.

Күп тә түгел, аз да түгел инде —
Җаныма яз сорыйм.
Җылы сүзсез, назсыз, җаңда язсыз
Мин барыбер корыйм, —
«Аллам бул!» дип сорыйм.

## СИНЕҢ ҖАНЫҢ

Яфрак-яфрак җан ямаулы,
Күз ямау сала җиргә.
Җан ямаулы, җир ямаулы —
Ямау салынмый җырга.

Искергән җаның, искергән,
Ямау да тота алмый.
Күзге яфраклар ябынып
Йоклап та китә алмый.

Сине күптән салкын үпкән,
Җаның ертылып беткән.
Ярый җырың ертык түгел
Халкың зарыгып көткән.

## ДИ-ВА-НА!

Бүген тагы син төшемә кердең:
Син яшь идең, мин дә яшь идем.
Мин тагы да киттем сине ташлап,
«Китмә» диеп, хет бер дәш идең...

Кайтыр идем кебек, кайтыр идем,
Син дәш идең...
                                        их, мин яшь идем!
Инде гомер буе менә шулай
Төшләр генә күреп яшимен.

Кояш көлә, җилләр әй уфтана.
Яфрак сөйли, чаган уйлана:
«Мәхәббәттән китү ул кәүсәңне
Ташлап китүдер бит,
Ди-ва-на!..»

## САГЫНУ

Башларымны кайнар күкрәгеңә
Салыр идем, бәгърем.
Хисләремне хисләремә кушып,
Кабыныр идем, Тәңрем...

Уйларымны уйларыма салып,
Уелып китәм ялгыз.
Йөрәгемнән ташкан хисләремне
Дәрьяларга салыгыз!

Суда батмас, утта янмас хис ул —
Кайнап чыгар дәрья.
Мәхәббәтне мөмкин йөгәнләргә
Бары икәү бергә.

Башларымны кайнар күкрәгеңә
Куяр идем — кайда?
Җылы эзләп тәрәзәгә килгән
Җаны туңган ай да...

## ТӨШТӘГЕ БӘХЕТ БЕЛӘН

Ярый әле син бар анда —
Башка берәүнең яры.
Синең хакта уйлыйм гына,
Кирәкми шуннан ары.

Синең дә хәлләрең шундый,
Мине уйлыйсың син дә.
Көннәр үтә, киләсең син
Бары төшләргә төндә.

Чынлап янган йөрәк өчен
Җитә хәтта төшләре.
Көннәре дә кирәк түгел,
Булмаса чын хисләре...

Ярый әле син бар анда,
Төшләр яшәтә мине.
Төшләремә иңеп калган
Сөю яшәртә мине.

Бәхетле булып уянам
Мин таңнарның барсында.
Аңлый алмый газапланам,
Ник син түгел каршымда?

Минем уянуны күргән
Күпләр өчен мин — тиле.
Ә миңа сөюдән мәхрүм
Калган күк бөтен иле.

Көннәр... төннәр... ак вә кара,
Җаннарда яра... яра...
Төшләремнең бер төндәге
Тик бер мизгелен кара...

Андый төшнең бер мизгелен
Карар өчен тик татып,
Дөньяның миллиардеры да
Алалмаячак сатып...

## СИҢА ДА, МИҢА ДА

Тәрәзәмнән кап-кара төн карый, —
Пешалмаган миләш.
Тәрәзәмнән мин дә төнгә карыйм, —
Төшалмаган кәләш...

Син дә карыйсың бит тәрәзәңнән,
Сиңа да карый төн.
Күрмәмешкә салынып сөйләшәсең
Алма белән тик син.

Мин дә төннең аен гына күрәм,
Ул да алма кебек түгәрәк.
Салкын айга кереп көярмен дип
Уйламаган бу җан-күбәләк.

Якын булгач, өздең алманы син,
Айны өзалмадың...
Ир булсаң да, үксеп еладың бит,
Ахры, түзалмадың.

Таң атуга, төн дә китеп барды,
Син тешләгән ай да югалды.
Күңел канатларын сыгып төшкән
Ачы алма булып уй калды.

## МИН ГЕНӘ

Мин сине яраткан кадәр
Ератсаң әгәр мине,
Таулар тез чүгәрләр иде, —
Яратмадың син мине.

Әгәр мин яраткан кадәр
Ярата калсаң мине,
Ай акылдан шашар иде, —
Яраталмадың мине.

Әгәр минем яратуның
Тамчысы булса синдә,
Җилләр тынып калыр иде,
Исмичә бу мизгелдә...

Ярый яратмадың әле...
Ае да көндәгечә.
Таулар горур карап тора,
Сызгырып җилләр исә.

Мин генә сөю алдында
Тезләнгән тау, шашкан ай.
Сөю тотып торган давыл,
Тоткындагы ташкындай.

## УЛ ЧАКТА ДА...

Ялгыз калгач, уйланасың:
Кемнәрне югалттым мин?
Күңелемне вакытлыча
Ни белән юаттым мин?

Кемнәрне югалттым да мин
Кемнәрне юаталдым?
Кемнәрнең күңелләреннән
Күңелемә ут алдым?

Бергә чакта уйланмаган,
Гел бергә булыр төсле.
Ялгыз калгач, уйлар кискен,
Ялгыз калгач, уй көчле.

Шатлыклар шашып шакыйлар,
Куышып килә кайгы.
Тәрәзәдән тотып алдым
Сагыштан тулган айны.

Күңел тәрәзәләремнән,
Әй, ялгыз ай, ник кердең?
Өермә купты күңелдә,
Очы качты фикернең...

Ул чакта да аны көттем —
Тәрәзәмә син килдең.
Ул чакта да ул килмәде —
Мин еладым, син көлдең.

Елатып китә белгәннәр
Юатмаганнар мине,
Юатканнар елатмаган
Һәм тапмаганнар мине.

## СИНЛЕ ФАСЫЛ

Бу салкыннар тәмам өшетте дип,
Көтеп алган идем быел җәйне.
Җәе килде челләләре белән,
Ташлап чыгалмадым никтер өйне.

Бу эсселәр тәмам туйдырды бит,
Инде көтәм көзләр җитүенме?
Туган җирдән өзелеп, өзгәләнеп
Инде көтәм казлар китүенме?

Сыгыла-бөгелә көздә елый таллар,
Ак карларны җылытасы бар дип,
Күз яшьләрен көмеш чәчәк итеп,
Салкын кышны яз итәсе бар дип.

Бу салкыннар тәмам өшетте дип,
Мин тагы да җәйне көтәрмен шул.
Кая икән синле ел фасылы? —
Көтеп ала алмый китәрмен шул...

# ГЫЙСЪЯН ТЫНЛЫК

Бүген өйдә шундый тынлык,
Юк, өйдә генә түгел,
Яфрак селкенер җил дә юк,
Юк, тышта гына түгел...
Җан вәйран, чиге күренмәс
Дала, юк, чиксез галәм...
Тынлыкны бозудан куркып,
Тукталып калды каләм...

Бүген минем өй ишеген
Ачып кермәс беркеме.
Җанга бирәр җан дәшмәсә,
Эзсез югалыр көне...

Җан югалткан көн озын ул,
Бер гомер кадәр озын.
Тынлык шулкадәр мәкерле,
Тынлык шулкадәр түзем...

Тәрәз каршында алмагач,
Дөнья тын да алмагач,
Төшерде бер алмасын, —
Башка кеше алмасын...

Алсын, алсын алмасын,
Алсын, нигә алмасын, —
Минем кебек тынлыкларда
Ул адашып калмасын.

Туп-туп итеп, ике аяк
Бозды урам тынлыгын, —
Алды да тешләп карады
Алмасының чынлыгын.

Пешкән алма пешкән шул,
Өзелепләр төшкән шул.
Пешмәгән алмасы — мин,
Өзә алмаганы — син...

Тәки дәштең җаныма,
Тагы боздың тынлыкны.
Кайларга гына куярга
Дөньядан бу чынлыкны?

Беркемне дә көтмәгәндә,
Җанга кертмәгәндә,
Кояш, тынлыкны бозмыйм дип,
Карны эретмәгәндә,
Алма тешләгән сандугач
Томшыгын кысмаганда,
Дөп-дөп итеп таптанасың
Син күңел почмагында.

«Сандугачым алма тешли,
Тешләсә дә кабалмый шул.
Минем күңелем сине эзли,
Эзләсә дә табалмый шул».

Тынлык тына, тынлык сына,
Тынлык түзем түгел шул...
Сине югалтканнан бирле
Үзем үзем түгел шул...

Тынлыклар гел шаулап тора,
Кычкырып тора тынлык:
Сиңа — ансыз, аңа синсез
Дөньяда юк ул чынлык.

## БАР ӘЛЕ

Төшкә керден,
Һаман чакырасың.
Ә мин икеләнәм, шикләнәм.
Юкса инде гомер... юк, әлегә
Ахырына килеп җитмәгән.

Җитмәгәндер.
Күрешергә кирәк,
Әйтер сүзләр калган телләрдә.
Болыннарга чыксам, тамчы-тамчы
Күз яшьләре икән гөлләрдә...

Сагына ул,
Сагына ул, диләр.
Итәк очларымны үбәләр...
Шул җилләрне булмый тик туктатып,
Гөлләремә сагыш түгәләр.

Гөлләрем лә
Түгел гөлләр генә,
Сагыш төсләрендә көннәрем.
Андый төсне әле дөнья белми —
Нинди төстә дисәң төннәрем...

Ялгызлыкның
Төсен таныйм хәзер.
Аккош көткән күлгә кара әле,
Мәңге кайтмасын да белгән килеш
Көтә белүчеләр бар әле.

## АХЫРГАЧА КӨТТЕК

Син йоклыйсың,
таң нурлары аз гына да оялмый,
үбә дә үбәләр сине,
үбә, үбеп туялмый.

Син йоклыйсың,
ай нурлары аз гына да оялмый,
керфек арасына кереп,
күз караңа оялый.

Син йоклыйсың,
таң нурлары тоташа карашыңа,
тагы да ялкын салалар
йөрәгем ярасына.

Син уяндың,
таң җилләре әллә телдән язганмы...
әллә таратып йөриме
дөньясына ялганны?

Таң җилләре:
«Сөйми» диләр, әллә «сөймә» диләрме?
Чәчләремнән сыйпап үтә
алар мине — юләрне.

Таң җилләре
алдашмаслар, алдамас таң нурлары.
Тыңла, тыңла — яңгырый бит
безнең йөрәк җырлары!

Син уяндың, —
әллә сизми, әллә сизми дисеңме? —
Таң нурлары пышылдыйлар
гүя минем исемне:

«Нәҗибә... Нәҗибә...» диләр
шулай гомер буйлары...
гомер ахырларынача
көттек инде туйларны...

## ГОМЕРЛЕК ГОМЕР

Гомер ничек үтсен инде,
Бер дә үтмәс төсле лә...
Бергә-бергә яшәгәннәр
Үтеп китмәс төсле лә...

Китүчеләр алар башка,
Безнең кебек түгелләр,
Менә шулай иләс-миләс
Яшь чагында күңелләр.

Сөелгәннәр гел булганнар,
Булганнар гел булачак.
Безнең йөрегән юлларга
Алар әле тулачак...

Һәм... бермәл китә сөйгәннәр —
Кителеп төшә күңел.
Елыйбыз: ник тиле дөнья
Без уйлаганча түгел?!

Күзләргә колак салабыз,
Күзгә керә сагышы.
Фасылларда мәгънә таба
Гомерләрнең агышы.

Һәм... бермәл китә якыннар —
Актарылып чыга җан.
Уйланыгыз дигән сыман,
Яшәешең кага чаң.

Кыш та салкын гына түгел,
Ак моңлы фасыл икән.
Әйлән-бәйлән төшкән карлар
Хыялдан хасил икән.

Көтмәгәндә чәчкә кунып,
Чал булып калса карлар,
Карашлар моңсуланалар,
Җитдиләнәләр ярлар...

Һәм... беркөн сиңа дәшәләр,
«Дәү әни!» дип, «Әби!» дип.
Күңел куырылып ала,
Шулай бул-дыда-мы дип...

Һәм... беркөн тормыш үзеңне
Таяндыра таякка.
Көтмәгәндә чалып ега
Икән вакыт аяктан.

Ә язлар һаман да килә,
Кайталар кыр казлары.
Әле яңа, бүгенгедәй
Тәүге сөю назлары...

Гомер ничек үтсен инде...
Үтсен дә китсен көзләр...
Кипкән яфраклар кыштырдап
Әйтәләр нинди сүзләр?

Кыштыр-кыштыр, алда кыштыр,
Вакытында иңик җиргә.
Җир җылысы мәңгелек ул,
Рәхмәт мизгел гомергә!

Гомер ничек үтсен инде?!
Үтмәде, дөнья — күздә.
Мәңгелекнең агачыннан
Коелдык кына без дә.

Гомер ничек үтсен инде?!
Без үттек дөнья буйлап.
Бакыйлыкта нәсел калу
Хакында уйлар уйлап.

## УЛ КИТКӘЧ...

Миңа бирәр исәр кирәк,
Исләрем киткән чакта,
Яз җилләре башларымны
Дивана иткән чакта...

Шул җан белән тоташырга
Һәм түгәргә хисләрне...
Мәхәббәт күрмәгәннәрнең
Китәр иде исләре.

Бөреләр яшь, аңламыйлар,
Ташкыннар ашыгалар —
Утырып калган бозлары,
Елгалар ташыганнар.

Кошлар мине тыңламыйлар,
Кошларның үз җырлары.
Таһир–Зөһрә, Ләйлә–Мәҗнүн —
Аларның үз чорлары...

Минем чор, минем мәхәббәт
Сыймый үткән, бүгенгә...
Кабынырлык көч аларда
Киләчәкнең күгенә!

Миңа бер... акыллы кирәк,
Сыйдыра алыр хисләрем.
Заман ярларыннан чыгып,
Таралсалар... нишләрмен?!

## ЭҢГЕР–МЕҢГЕРЛЕ СӘГАТЬ

Ничек кенә карышсам да,
Уба мине бер халәт.
Шундый халәткә керәм мин,
Җитте исә бер сәгать...

Башта эңгер–меңгер төшә,
Аннан калка күктә ай.
Һәм теге халәт үрмәли,
Бер тамчы да аямый.

Менә анын белән бергә
Кайтып киләбез өйгә.
Яфраклар шыбырдашалар
Нәкъ без уйлаган көйгә.

Урак ай күккә эленгән,
Бер йолдызы янында.
Без икәү бар дөньясында,
Ни кирәк сон тагын да?

Без бик сирәк сөйләшәбез,
Ә күнелләр серләшә.
Серләрне сергә беркетеп,
Бер төн кошы эндәшә.

Бер–беребезгә карашмыйбыз,
Бары тик елмаябыз.
Сүзгә кош кушылуын да
Инде без уйлаганбыз.

Без гүя кыз белән егет,
Тотынганбыз кулга–кул.
Күнелләр бер–берсен тыя:
Әле урам, сабыр бул!

Күнелләргә буйсынсак та,
Без инде йөгерәбез...
Сулуыбыз капкан килеш
Өйгә кайтып керәбез.

Һәм... син: «Айдан качтык, — дисең, —
Яфраклар да кысылмый.
Юкса уйлап өлгермисең,
Шул төн кошы уфылдый...»

Өйгә ут элендермибез,
Чәй... ансы көтәр әле.
Тәрәзгә килгән ае да
Оялып китәр әле.

Сөю сүзләре барыбер
Каләмнән саркып чыга.
Күз йомып ачкан арада,
Офыктан кояш чыга.

Ай белән кояш та сүзсез,
Сүзләрен кем ишеткән?
Җанда шигырь — шыбыр-шыбыр,
Без чыгабыз ишектән.

Ничек кенә карышсам да,
Уба мине шул халәт.
Шундый халәткә керәм мин —
Эңгер-меңгерле сәгать...

## ЗӨЛФӘТ-МӨДӘРРИС

Китте...
Коелыплар төште
Милләт иңендәге
ике канат.
Яра урыннары
тора канап...

## Ә ТАҢ АТТЫ...

Бүген таңда уяндыңмы, әйтче,
Син күрдеңме кара болытларны?
Таң кызлары шәмнәр тотып йөрде,
Караңгылык йотты ул нурларны.

Әй болганды болыт ачуыннан,
Күктә котырынып ташкын ташты.
Ташкыннарны өзеп-өзеп алып,
Көз җилләре җиргә карлар атты.

Ә таң атты, атмый каламыни!
Атты, әмма алсуланмый гына.
Кояш карап торды шул хәлләргә
Мәгъруур гына, ачуланмый гына.

Һәм көн туды. Кара сыннар — кара,
Аклары — ак, сорылары — соры.
Таңны аттырмаслык хәлләр белән
Тагы күзгә килеп керде чоры.

Бүген таңда уянмадың, бәгърем,
Әллә күрми калдың син шуларны?
Җиргә ятып эчте көз җилләре
Күз яшьләре диеп шул суларны.

Яңа таңда кабереңә килдем...
«Тыныч йокла, бәгърем», — дигән идем,
Син кычкырып... көлдең...
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Үз хәлемне үзем генә белдем...

## ҮР ҺӘМ ГҮР

Миңа ниләр булды икән? —
Кулымнан төште эшем.
Миннән мәңгелеккә күчте
Мине яраткан кешем.

Миңа ничек яшәргә соң? —
Киткәннәр кире кайтмый...
Көн тудымы, аякларым
Аның янына атлый...

Инде сәерсенеп карый
Каберлек караучылар.
Беләм лә, миннән башка да
Каберен караучы бар...

Кабер... мин аны күрмим дә,
Мин сине генә күрәм.
Ишекләре булмаса да,
Синең гүреңә керәм...

Гүр ияләрен җыеп, син
Шигырь укыйсың икән...
Син анда да һаман да бер
Сүзне тукыйсың икән:

«Коллык кайда да коллык ул
Кабул иткәннәр өчен,
Хөрлек кайда да хөрлек ул
Хөррият көткән өчен!

Көтмәгез, — дисең, — бер мизгел
Өзәр диеп барсын да.
Син чишәсе төеннәрдән
Мәңгелек бар каршыңда.

Кешегә фәкать ике юл:
Фанилыкта — гел үргә.
Икенчесе — бакыйлыкта, —
Керергә тиеш гүргә.

Үр дә, гүр дә бер тамырдан, —
Кеше очарга тиеш.
Ирекле туган туфрагын
Ахыр кочарга тиеш».

Мин дә нәкъ шундый фикердә, —
Хәлләреңне аңлыйм бит.
Кочкан туфрагыңа гына
Ирек яулый алмыйм бит...

Миңа ни булганын беләм, —
Чарасыз мин коллыктан.
Үргә талпынамын һаман
Гүргә башка юл юктан.

## УЙ ДУЛКЫНЫ

Мин яраткан әнә ярда ята,
Ул бит балык иде судагы.
Ул бит инде күптән мәет, беләм,
Тик терелтә аны уй тагы.

Ышанасы килми, ышаналмыйм
Дулкын ташлавына ярларга.
Давыллар да төшә кебек төпкә
Аны, аны гына барларга.

Күпме дулкын, күпме суүсемнәр,
Карурманнар, киек җанвары —
Аның җан ярсуын тыңлады да
Гайрәтләнә төште җаннары.

Мин яраткан, әйе, мине сөйгән
Хис йомгагы әллә сүнгәнме?
Ышаналмыйм, юк, юк, ышаналмыйм, —
Әллә шигырь үзе үлгәнме?

Җил-давылга дулкын рәхмәт укый,
Үбә-үбә аның җәсәден:
«Безнең кебек өйсез ятим булдың,
Тик ирекле булып яшәдең...»

Җил-давылга мин дә җаным сонам, —
Тормыш дулкыннары рәхимсез...
Сагышларны юып алып китми,
Калалмый, дип, җәсәд каберсез...

Җәсәден дә дулкын суырып алды.
Кычкырамын: кирәк кабер, дим...
Дулкын шаулый, диләр, сөйли икән:
«Кирәк иде кадер, кадер!» — ди.

Мине сөйгән, мин яраткан җанны
Дулкын тибрәтер дә тибрәтер...
«Сабый җаның тагы бишегендә —
Мәңге тибрән...» — диеп ул әйтер.

Мине сөйгән әнә бишегендә, —
Сабый җаны өчен яраттым.
Мин бит бары аның ише генә, —
Яннарына салчы, йа Раббым...

## НИ СӨЙЛӘР МӨДӘРРИСЕҢ...

Тукайҗан, баргач, әрнүен
Сөйләр бер Мөдәррисең.

*М.Әгъләм*

Сөйлидер Мөдәррис анда,
Ышан ла, Тукай җаным!
Булдырыйм диеп дөньяны,
Ул үзе бетте янып.

Аны озатып кайтканда,
Тойдылар — дөнья салкын.
Җылытырга аладыр җир
Куйнына шагыйрь халкын...

Тукай белән очрашуың
Төшемә керде кичә.
Сүзләреңне язып куйды
Минут кичектермичә:

«Кояшны кырык кат болыт
Капласа да, таң атар.
Бу дөньяга татар булып
Туган һәр кеше батыр».

* * *

Мин сине бары дөньядан
Киткәч кенә онытырмын...
Оныталмам, йөрәгемне
Синең өчен он итәрмен...

## ЙӨРӘК ГӨЛЕ

Дөнья татлы, дөнья ачы,
Кайнар, зәмһәрир салкын.
Үзем дә сизми, җанымны
Сөю утына яктым...

Сөю уты юлындагы
Бар нәрсәне яндыра.
Фанилыкта шушы хакта
Җырларга җыр калдыра.

Сөйгәннәрдән, бәлки, җирдә
Каладыр йөрәк көле?!
Мин киттем... йөрәк көлемдә
Тибрәлә йөрәк гөле.

## МИН ЫШАНДЫМ КОШКА...

Нәҗибә дә кошлар нәселеннән.
*М.Әгъләм*

Син барында җирдә, җир йөзендә,
Җир йөзенең хет кай тарафында,
Ялгыз түгел идем җир йөзендә.
Белә идем, барыбер иртәгәсен
Аккош күленә лә барасымны...

Син барында җирдә, җир йөзендә,
Кояш чыга иде канатланып.
Кояш канатына тотынып ла
Оча идек ничекләр шатланып!

Беркем күрми иде, сизми иде:
Җир йөзенең хет кай тарафына
Очып төшеп җиргә баса идек
Кабат-кабат җаннар ярасына...

Икебез дә шундый исәр идек,
Таптап торсалар да үсә идек.
Тәүлек дәвамында ничә тапкыр
Күккә менеп җиргә төшә идек.

Төшә идек... әллә бу менүдә
Онытгыңмы җирдә мин барын?
Ярсып-ярсып ташыды да җаның,
Ташлап чыгып китте җир ярын.

Син барында җирдә, җир йөзендә,
Кояш мәхәббәттән яна иде...
Фани дөнья — кадим, ләкин безгә
Һәр мизгеле аның яңа иде...

Син барында җирдә аккош идем,
Син киттең дә, җанга ак кыш инде...
Тәрәзәмә бүген песнәк кунып:
«Бәгырькәем, мин бит монда», — диде.

Әгәр ышанмасам кош сүзенә,
Яши алмам минут җир йөзендә...
Җан — мәңгелек, инкяр италмыйлар,
Мин ышандым нәни кош сүзенә...

## КАЙТА ИКӘН

Кем уйлаган таңда кояш
Син булып чыгар диеп?
Кем уйлаган күктә аем
Син булып туар диеп?
Кем уйлаган бары шулар
Кайгымны куар диеп?

Кем уйлаган уйларны тик
Уй гына куар диеп?
Кайгыларны бергә кушсаң,
Шатлыклар туар диеп?

Уйламаган, шуңа да шул
Ачылмаган бу канун:
Шатлыклар кайталар икән,
Ачык торса хөр җаның.

Мәхәббәткә, ачык җанга,
Бары тик сөйгәннәргә,
Сөйгәненең йөрәгенә
Җыр булып иңгәннәргә

Кайта икән сөю җыры,
Кайта сихри моң булып.
Бәхет мизгеле яңгырый
Кайтавазда мең булып!

# V

*Сөю янында галәм —*
*Бары кулдагы каләм...*

## ЫЧКЫНАСЫМ КИЛӘ...

Дөньясына бер нәгъръә орып,
«Яратам!» дип килә кычкырасым.
Һаман саен нигә кабатлыйсың:
«Сөю-мәхәббәт дип ычкынасың...»

Бар хикмәт тә шунда, әйтсәм әйтим:
Ычкынасым килә минем... Җирдән!
Канат җәеп бер очасым килә,
Шатлыгымнан шашып көлә-көлә.

Кайтавазы булып көлүемнең
Күкләр күкрәп, яшен уйнар иде.
Канат җилләремнән чайпалыр да
Ак болытлар иңгә кунар иде.

Шигырь каурыйларым арасыннан
Салават күпере салыныр да,
Син килерсең миңа Акбүз атта,
Вакыт булды инде сагынырга.

Нур-тәхеттә очрашырбыз шулай.
Мәхәббәткә җир-күк шаһит булыр.
Бары сөю канатында гына
Җирнең тартуыннан качып булыр.

Җир әйләнә шундый сөю эзләп,
Күкләр елап, көлеп, күкрәп тора.
Ышанмасаң шундый хикмәт барга,
Мәңге сөю көткән айдан сора...

Ай бит үзе җирдән ычкынган зат —
Гашыйк җаннар табына торган нокта...
Ычкынабыз бугай сөю эзләп,
Ялгызлыктан тагы ялгызлыкка.

## НӘНИ ГАШЫЙК

Алты яшьтә гашыйк булган идем
Күршедәге чибәр малайга.
Хисләремнән беркем көлалмады, —
Серләремне салдым мин айга.

Алты яшьлек минем яшьтәшләрем
Аңламады мине ул чакта.
«Гашыйк булу әкият икән» диеп,
Мин җыр язган идем шул чакта.

«Бу әнкәйләр җырлый торган җыр» дип,
Җырламады аны берсе дә.
Әмма аны отып алган иде
Серле егет кенә күршедә.

«Гашыйк булу әкият икән» диеп,
Күрше егет һаман моңланды.
Минем җырны койма аша гына
Күрше апа качып тыңлады.

«Гашыйк булу әкият икән» диеп,
Кичке урамнар да суздылар.
Безнең өй турыннан әнә ничек
Мине күрми генә уздылар.

Миңа — алты, ә аларга инде,
Ә аларга инде — уналты.
Әмма йөрәкләрдә уртак иде
Җыр тудырган изге бу ялкын.

Инде менә миңа алтмыш була.
Оныгыма тула уналты.
«Гашыйк булу — әкият» дигән җырны
Бер тыңлауда отып ул алды.

Һәм ул җырлый, ә мин тыңлыйм гына
Күрше бүлмәдәге гашыйкны.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ник, Мәхәббәт, миңа шулкадәрле
Иртә килдең, нигә ашыктың?

Ә барыбер сагынам иртәләгән
Алты яшьлек бөек гашыйкны.

## КАЯ УЛ...

Әллә ниләр булды миңа, —
Җыр ага, җаннан ага.
Җанымны, яшьлектән кайтып,
Утлы мизгелләр чага.

Урам чаты... бакча арты... —
Аһ, үбә, янып үләм!
Итәкләргә чыгып түкте
Койма буенда үлән.

Төн оялды да кызарды —
Ничек тиз ата таңы.
Ник оялдым, ник бер чынлап
Кочакламадым аны...

Шулкадәр ярату тулы
Җанны тыйдым бит, тыйдым.
Капканы борын төбендә
Шап итеп ябып куйдым
Һәм... үзем елап җибәрдем,
Ә ул нишләде икән?
Кагылмый гына янымда
Басып торгач та җиткән...

Кагылма, кулга да тимә! —
Үпкәләп китәм хәзер...

Үпкәләтеп үпкән булсаң,
Ни булыр иде, бәгырь?..

Хәзер генә шулай дим дә,
Ул чакта, һай, кая ул!
Йа Хода, ул! —
Пәрдә артына качып калдым...
Үтеп китте бая ул...
Инде хәзер... —
Кая ул...

## КӨТКӘНДӘ

Әй, нигә сызгырып үттең,
Тиле җил?
Минем аңа хәбәрем бар, —
Бире кил!

Әй, нигә миннән көләсең,
Кояшым?
Аның карашларын килә
Тоясым...

Әй, кагылма яфракларга,
Җил генәм!
Серле куллар иркәли бит,
Мин беләм...

Ни хакында пышылдыйсыз,
Тирәкләр?
Әйе, монда аны көткән
Йөрәк бар.

Нишлисең, җил, ник китердең
Болытны?
Әллә аның йөрәгендә
Мин юкмы?

Күк, елама, кер җаныма —
Сыйдырам.
Мин еламыйм, мөлдерәмә
Тик торам.

Әй, сөюдән түтелергә
Җиткәннәр!
Мәхәббәттән миндәй газап
Чиккәннәр! —
Тимәгез җилгә, кояшка,
Болытка!
Дөнья моңсу, дөнья елый
Ул юкка...

Аһ, кояшым кереп килә
Ишектән, —
Хәбәремне, хәлләремне
Ишеткән!

Тәрәзәмне ачып керде
Җил өйгә.
Бар дөньясы җырлап тора
Бер көйгә!
Һәрбер яфрак сөю көен
Пышылдый:
«Чын мәхәббәт була, — диеп, —
Шушындый!»

## МӘХӘББӘТ ТӨТЕНЕ

Үткән гасыр Алсуына
Гашыйк иде Такташ,
Безнең заман Алсуына
Җыр багышлый Гаташ.

Алсу, сеңлем, син алданма
Шагыйранә сүзгә.
Безнең яшәү, безнең заман
Ул бөтенләй үзгә.

Хәзер... мәхәббәт сүзеннән
Төтен керә күзгә...

## ЧИШЕЛҮ

Яшьлегемдә мин дә синең кебек
Илаһилык эзләп оча идем.
Җирне–күкне йолдызлары белән
Кочагыма алып кыса идем...

Йолдыз яңгырларын эчә идем,
Җәяү йөри идем болытларда.
Сөйли иде миңа һәрбер яфрак,
Серен чишә иде балыклар да.

Мин аларга якынрак килдем,
Алар буй җитмәслек биек икән.
Мин уйлаган нәүмиз табигатьтә
Уй җитмәслек бик күп киек икән.

Каурый болытлары түбән төште,
Үзе басты минем күңелемә.
Әллә кемнәр әлләниләр кылды,
Ышан, диеп, үзең түгеленә...

Болытларны иңнәремдә тотам,
Бары шуның белән генә отам.
Мин яраткан, мине сөйгәннәр дә
Калышалар әле миннән тотам.

Әллә кемнәр әллә ниләр әйтте.
Әйткәннәре шундый хак булды...
Сүзләренә хәтта шикләнми дә
Чындыр дип ышанган чак булды.

Бары бер нәрсәгә ышанмадым:
«Син бит үзең түгел» дигәннәргә
Һәм ышандым йолдызларны үбеп,
Сөю ялкынында көйгәннәргә.

## ТАБЫШМАК ТҮГЕЛ

Утта янмый, суда батмый, —
Ул нәрсә?
Күккә очмый, җилне кочмый, —
Ул нәрсә?
Йолдызларны йөри һаман
Аралап
Йә җаннарны берәм-берәм
Яралап.

Бу да үтәр, диеп әйтмә, —
Үтми ул.
Фәйләсуфның канунын да
Читли ул...
Көтеп килми, куып китми, —
Шундый ул.
Ансыз, яшәдем дип, яшәп
Булмый шул.

Буйсындыра патшаны да,
Колны да.

Саташтыра һәрчак белгән
Юлны да.
Мин ризамын буйсынырга,
Буйсынам.
Ул килгәнче мин кол идем,
Хәзер — хан!

## МИН СӨЙДЕМ...

Үз иркем белән адашам
Кереп карурманнарга.
Исем дә китми туктаусыз
Бүреләр улаганга.

Үз иркем белән адашам,
Бураннар күмсен мине...
Буран дулап, бүре улап
Оныттырачак сине...

Язгы ташуларга төшәм,
Агызып алып китсен...
Мәхәббәт уты сүнгәнне
Ни-нәрсә кабул итсен...

Ярга ташлады ташкын.
Тынды урман — шауламый.
Кушылыплар улар идем,
Сыңар бүре уламый...

Җанда кабынган янгынны
Юк сүндерү чарасы.
«Мин сөйдем — җәзала!» — диеп,
Бер Ходага барасы...

## КАРЛАР ДА БЕЛМИ

Әкрен генә җиргә карлар төшә, —
Капланалар эзләр.
Күңелләрдә ләкин уелып кала
Үткән елгы сүзләр.

Әкрен генә җиргә карлар төшә, —
Ап-ак чәчәк гүя.
Күтелмәгән түбә-үрләренә
Көмеш таҗлар куя.

Әкрен генә җиргә карлар төшә, —
Керә алмый җанга.
Җиргә салган эзләр яңаралар,
Яңару юк җанга.

Әкрен генә җиргә карлар төшә, —
Тапталасын белми...
Җирдән кабат күккә ашкач кына
Акланасын белми...

## КУНАК МИЗГЕЛ

Оныгым кунакка килде, —
Бар дөньяма нур инде.
«Нәнәем, — ди ул, — мин килгәч,
Син бераз яшәр инде!

Сиңа сөйләр серләрем бар,
Тизрәк китсә икән кар...
Яшел үлән өсләреннән
Йөгереп йөрисебез бар...

Җәйгә чыккач, җәйге ялда
Хәмит белән болында,
Син сөйләгән теге серле
Пар тирәкле урында

Очрашырга сүз куештык, —
Ул ярата бит мине...
«Болынның иң матур гөлен
Бүләк итәрмен», — диде.

Күз алдымда җәйге болын
Пәйда булды да куйды.
Оныгым яшьлеккә таба
Борды да куйды уйны.

Ул сөйли киләчәк көнен,
Мин сөйлим үткәнемне.
«Җаныем!» — ди, кочып үптем
Оныгым-үскәнемне...

Оялып кып-кызыл булдым, —
Кайттым бит яшьлегемә...
Кемне кочып үпкәнемне
Әйталмыйм... әйтмим генә.

## ҮЗГӘРМИ ҮЗГӘРТӘЛӘР...

Мәхәббәтне алтын димә,
Алтын шундый салкын.
Үзе үзгәрми үзгәртә
Ләкин адәм затын.

Чын мәхәббәт тә үзгәрми,
Тик үзгәртә җанны.
Алтын салкынын тойдымы,
Ташлап китә аны.

Үзгәрми үзгәрткәннәрне
Таный алмадыңмы,
Үзең дә сизмәячәксең
Җансыз калганыңны...

## КӨНЛӘШУ

Син килмәдең. Көзге моң эчендә
Берьялгызым йөрдем төнката.
Кара көзнең һәрбер почмагында,
һәрбер шәүләсендә сер ята...

Мин ялгызым. Шәрә тынлык кына
Сарыла да җанга сарыла.
Тынлык дәрьясында йөзгән сыман
Барыла да һаман барыла...

һәм... алдымда көтелмәгән кунак, —
Тирә-якны күрми, ишетми.
Ник йокыга һаман талмаган ул? —
Энә йомгагына ни җитми?

Мин туктaлдым, ул да туктап калды,
Аякларыма ук сыенып.
Кагылмыйча торам энәләргә,
Торам кадалудан тыелып...

Күреп алдым керпе күзләрендә
Әллә нинди моңмы, сагышмы...
Кулларыма алдым һәм өемә
Алып кайттым төнге табышны.

Сөт эчте дә керпе чыгып китте.
Аны көтәләрдер урманда...
Шәрә тынлык, җаным шундый туңа,
Җылыталмый мамык юрган да.

Мин ялгызым. Салкын шәрә тынлык
Җанга кереп оялмасын...
Гомер көзләрендә шул керпедән
Көнләшерлек көнгә калма син...

## ҖАН ҺӘМ ЯЛГЫЗЛЫК

Камчылап куып чыгарам
Җаннан мәхәббәтеңне
Һәм сабак итеп яшәрмен
Алган җәрәхәтемне...

Көзге сагышлар өстенә
Сагышлар өйдең нигә?
Ялгызлыгым өйгә керми,
Минсез мең газап чигә.

Юкка мине ташлыйсың, ди,
Юкка гына куасың.
Белмисең, ул мәхәббәттән
Яңа газап туасын...

Миннән тугры дусны табу
Мөмкин түгел, аңла, ди.
Алтын таулары бирсә дә,
Кирәк түгел, алма! ди.

Җан тыпырчына, карыша,
Мәхәббәтсез булмый, ди.
Яшәп кара мәхәббәтне
Син үзеңнән кумый, ди.

Ике иңдә пар фәрештә,
Юк, Мөнкир белән Нөнкир.
Җанга сөю тулган килеш,
Имеш, япа-ялгыз йөр...

Күтәп алган мәхәббәттән
Гомер азагынача,
Әйт инде, әйт, нинди тиле
Минем шикелле кача?

Куып кертеп тә булмый,
Чыгаралмыйсың куып.
Җан чыгып китәдер инде
Шул тартышудан туеп...

## БАШКА ЧАРА ЮКТЫР

Әллә тойдың бөреләрнең
Күз яралып калуын,
Йөрәгеңнең мәхәббәттән
Яшәү яме алуын?

Әллә тойдың әлегәчә
Әле яшәмәвеңне,
Йөрәгеңне аңламаган
Өчен дәшәлмәвеңне?

Әллә соң гамьсезлегеңне
Куды йөрәгеңнән гамь?
Бары мәхәббәт китерә
Фани дөньяларга ямь.

Килим, дисең, яннарыңа,
Шундый килә күрәсем.
Белмәгәнмен, килә икән
Янган утка керәсе...

Утны утлар яндыралмый,
Әллә сүнәсең килә?
Сүнәрбез, әмма барыбер
Янып сүнәсе килә!

## МӘХӘББӘТКӘ

Миндә тик бер җанлык сөю,
Бер йөрәклек талпыну.
Йөрәк шулай яши белә, —
Анда кояш ялкыны!

Үрелмә, дисәң дә, үрли,
Кояшта чертләп яна.
Йолдыз яңгырлары булып
Төшкән хисләрем яңа!

Бары бер йөрәк эченә
Кояш та сыя ала.
Утны — ут, ә мәхәббәтне
Мәхәббәт тыя ала...

Шул мәхәббәтне тапканчы,
Җанда кояш батканчы,
Талпыначак бу йөрәгем,
Әй, мәхәббәт, алдакчы...

Ник мине читләп йөрисең,
Күзләрне күрмисеңме?
Бикле җаннарга шакыйсың,
Ачыкка кермисеңме?

Гомер ахырына кадәр
Сине көткән юләргә
Утлы гөрзиең белән ор! —
Риза янып үләргә...

## СУКЫРАЙТА

Мәхәббәт шундый хикмәт ул —
Ямьсезне матурайта.
Көрәк сабы кадәрне дә
Алып батыры итә...

Мәхәббәт шундый әкәмәт —
Күренми кара акта.
Колакка керми сүзләр дә,
Үлеп яраткан чакта.

Мәхәббәт шундый икән ул —
Томалый ике күзне.
Әйталмый азапланасың
Акылың кушкан сүзне.

Тик бермәл акыл ача шул
Томаланган күзләрне.
Телеңне тартып әйттерә
Үзе кушкан сүзләрне:

«Һушыңа кил, әй, хис колы!
Абынма, — ди, — түмгәккә!
Баһадирым дип табынма
Эче буш бер күлмәккә!

Тормыш усал, ул кичерми
Җанга кергән бушлыкны.
Юып кына алып булмый
Бушлык салган тутыкны!»

Шап итеп җиргә төшереп
Бастырып куя акыл.
Тик инде чертләп өзелә
Җанында нечкә бер кыл.

Җан яралы, ялгышыңа
Түлисең шундый хакны,
Вакытында аералмагач
Шул кара белән акны.

Күздән яшь түгел, күңелдән
Коела борчак тозлар...
Җанны ямап булмас ансы,
Тик сезгә әйтәм, кызлар!

Хис дәрьясына онтылып
Керепләр чумган чакта,
Карада ак күренсә дә,
Күренми кара акта...

Онытмагыз шул хакта!

## СИНМЕ, СӨЮ?

«Киләм», — диеп дәштең, шул мизгелдән
Күңел бары көтү халәтендә.
Әллә инде җилләр исми тора,
Ук туктаган минем сәгатемдә...

«Киләм», — диеп дәшкән мизгелендә
Җан йөрәккә фәрман бирә кебек.
Йөрәк шулчак кинәт бәреп куя, —
Аякларга кадәр китә биеп.

«Киләм», — дигәч, ничә сәгать үтте! —
Минутлары аның елмыни...
Һәм күңелгә тагы сорау керде:
Гомерең буе көткән улмыни?

Көтәм сине, хыялдагы сөю!
Сине көтәм, «Киләм», — диден дә...
Гомер көзем кышка кереп бара...
Ә мин һаман ялгыз — өемдә...

## СОҢЛАГАН МӘХӘББӘТ

Мин сине барыбер көтәм,
Килсәң дә, килмәсәң дә,
Шулкадәрләр көткәнемне
Белсәң дә, белмәсәң дә.

Беркемне дә көтми генә
Узган мизгелләрем җәл.
Сөю читләп үтте димәм,
Инде килсә дә әҗәл...

Син килмә, сөюең күптән
Кереп урнашты җанга.
Син әлегә генә шулай
Йөрисең сукмый санга...

Башкаеңа аякларың
Буйсынмас көннәр алда.
Әлегә «вакыт җитмәде»
Йә «арганмын» дип алда!

Мин сине барыбер көтәм,
Көмеш чәчле ай улы!
Хата «бу да үтәр» дию,
Килде. Китмәс бу юлы...

Китү өчен вакыт та тар,
Кыскарган барыр юл да.
Соңгы туй атлары инде
Килергә чыккан, юлда...

## ЯШИМ ӘЛЕ

Яфраклар яшел әле.
Күкләрдә яшен әле.
Бу юләр мәхәббәт көтә,
Оныткан яшен әле.

Мин түгел, күңел бит ул,
Ник шулай шаштырадыр?
Бикләнгән ишекләрне дә
Ник кабат ачтырадыр?

Яфраклар яшел булса да,
Кире кайтмас бөрегә.
Бөре эченнән мәхәббәт
Дәшә: «Мин, — дип, — биредә!»

Яфраклар яшел әле.
Мәхәббәт хушлашмый икән,
Димәк, мин яшим әле!

VI

*Зарларымны кыссам — җыр чыга,*
*Башка язмыш юктыр җырчыга.*

## КОЯШ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

— Исәнме, әй, саумы, кояш!
Ни хәлләрең бар?
Мин җирдә, исән-сау да ул,
Дөньям тулы зар.

— Мин исән-сау әле, бәндәм,
Елыйсың икән.
Син дөньяны яктыртырга
Уйлыйсың икән.

Миңа карап уйлан әле,
Әй, бәндәм генәм.
Нидән мәңге утта яна
Кояшың гелән?

Үз-үзеңне кабызмасаң,
Дөнья караңгы.
Чакматаштай кабыналсаң,
Ямыйм яраңны.

* * *

Күк шәмәхә. Кып-кызыл ай
Тик урак кадәр генә.
Иссә җил, кузгалыр болыт,
Югалыр хәзер менә.

Кара болыт ертыклары
Кунганнар ак каенга.
Ап-ак шатлыкларны гүя
Батырганнар кайгыга.

Күк шәмәхә. Каеннар ак.
Ертык болытлар кара.
Ак каенның кәүсәсенә
Кемдер ясаган яра.

Таң. Күк — алсу. Каен — кызыл,
Кан ага ярасыннан.
Гаепләне эзләп йөрим
Кешеләр арасыннан.

Кич. Барыбер кара җиргә
Түшәлә ап-ак томан,
Кара җаннарны акларга
Тырышкан шагыйрь сыман.

## МИН КЕМНЕКЕ?

Кычкырасың:
Мин — Алла да мин — Алла!
Танымыйм бит, әй Алла...
Буласың килсә Алла,
Алалыгымны аңла!

Ай — минеке, минем кояш,
Минем йолдызым күктә!
Унын, йөзен ала алам,
Теләсәм, күберәк тә!

Минем Тукай, минем Такташ,
Кол Гали дә минеке!
Минем Пушкин, Есениным,
Минеке һәм синеке!

Буй җитмәслек, уй җитмәслек
Нурдыр, йолдыздыр алар.
Мин сокланган саен, беләм,
Алар яктырак янар.

Кояш якты. Кояш кайнар,
Беркем кояш булалмый.
Ае якты, ае салкын,
Беркем дә кагылалмый.

Бары күңелләргә тула
Нур булып та җыр булып,
Тик яшәгәннәрдер алар
Башта бездәй җир булып.

Җир булып сүнгән дигәнгә,
Юк, килми ышанасым!
Әллә килми кешеләрнең
Кояш булып янасы?!

Йолдыз булып кабынасы
Галәмнең карасына,
Җыр булып иңәсе килә
Җаннарның ярасына.

Кояш җирдән күтәрелгән,
Йолдызлар бар да җирдән!
Җаннар күрер, кабул итәр
Илаһи ихлас җырдан.

Кайсы ерак, кайсы якын, —
Тик төрле-төрле чордан.

Минеке дип әйтә алам
Ерагын, якынын да.
Ә кемнең җылынганы бар
Йолдызлар ялкынында?

Сызган җаннарның иҗаты
Сызгыч инде җаннарга.
Җан җаннарга орынудан
Кояш кабына таңнарга.

Орынырга тырышабыз
Тукайга да Пушкинга.
Әверелергә телибездер
Кояш каны — очкынга.

«Минем Тукай, минем Пушкин,
Минем Такташ, Туфаным,
Минем Саҗидәм, Нәҗибәм!» —
Дисә рухи туганым,
Йолдыз булып кабынырмын,
Балкырмын кояш булып.
Җаннар яктыралар бит ул
Бары бәхеттән тулып!

Юк, минем буласым килми
Пушкин, Тукай, Есенин...
Мин — башка, кешеләрем дә, —
Башка чорда яшимен.

Мин бәхетле була алам,
Булып калалсам үзем,
Әйтә алсам кешеләргә
Үз заманымның сүзен.

Менә шулай, хәзрәти Пушкин!
Менә шулай, Тукай дустым!
Миңа халкым, миңа чорым
Үзем булырга кушты!

## ЯШЬЛЕККӘ ДӘШҮ

*Агроуниверситет яшьләренә*

Исәнмесез, саулармы?
Җанда янар таулармы?
Безнең йөрәк ярсуларын
Сезнең йөрәк аңлармы?

Әйтеп карагыз, дисезме,
Йөрәкнең ни диюен?
Аңлатырга тырышыйммы
Нидән аның көюен?

Һәрчак югалтканын эзли,
Тапмыйча тынмый кеше.
Инде ул бишенче гасыр
Милли дәүләтсез өши.

Югалтулар шулкадәр зур, —
Төшмәс өчен төпләргә,
Канат куярга мәҗбүр без
Мәңге очмас күпләргә...

Данны түгел, җан сакларга
Түгелә, аһ, көчебез...
Яшәми бакыйга күчә
Шулай күпме кешебез!

Тарихның сират күперен
Кичү чоры татарның.
Кирәк икән, шул күпергә
Басма булып ятармын!

Нык булса минем үзәгем,
Милләт басып атласын.
Тик туар таңнары гына
Үздәүләтсез атмасын!

Үз илендә, үз җирендә
Сөйләсен үз телендә.
Рухи афәт — болай яшәү
Ата-баба көлендә...

Минем җанда бабайлардан
Кабынган ялкын үрли.
Аһ, тик мин дә китеп барам
Үз дәүләтемне күрми...

Алыгыз сез шул ялкынны! —
Алыгыз җаным белән!
Шагыйрь җиргә шул ялкынны
Тик күчерергә килгән.

## ТЫҢЛАГЫЗ БУ МӘДХИЯНЕ

*(Замана бәете)*

> Котырган эт һауа карап өргән менән
> Асманда торган айның нуры китмәс!
>
> *Акмулла*

Никтер мәдхия язмыйбыз,
Әллә данлар эшебез юк?
Данлар эшләрне аңлардык
Әллә аңлы кешебез юк?
Кыюлыгым җитеп, бүген
Үз сүземне башлыйм әле.
Исем куям «Нурихан» дип,
Тыңлагыз бу мәдхияне,
Ул — заманым пәйгамбәре.

Туган туфрагыңның даны Син,
Бәгыреннән тамган каны Син.
Тарихының татлы җимеше.
Халкың өчен булды һәр эшең.
Ай-һай, саллы керткән өлешең.

Тарих төпләренә төштең Син,
Милләтеңнең алтын төше Син.
Милләтеңә тарих капкасын
Ачу юлын эзләп тапкансың.
Эзләп табып... белеп каккансың.

Син тын аккан тирән Иделдер,
Син Каф тавы, бәлки, Уралдыр?
Халкың җаннарына керү дә
Төш кенәдер, төшне юраудыр.
Үткән юллар шулай ураудыр.

Син Әтилдер, бәлки, Чулмандыр?
Хәзәр диңгез, бәлки, океандыр?
Сиңа шундый фәрман иңгәндер:
Милләтеңә канат син куйдыр!
Аның өчен син тик бер сыйдыр.

Милләтеңнең рухи таҗы Син!
Милләтеңнең йөзек кашы Син!
Милләт тарихының хакыйкый
Нәфис елъязмасын ачтың Син!
Чүп–чарлардан читкә качтың Син!

Бар язганың, иңеп җаннарга,
Өмет уты булып кабынды.
Заман пәйгамбәре — Нури хан,
Милләт сиңа ихлас табынды.
Сүнеп бара иде — кабынды.

Котлы булды барлык язганың,
Вөҗдан кушмаганны язмадың.
Котлы булды гамәл, уең да,
Котлы булсын гомер туең да!
Шундый теләк милләт уенда!

## ҖАНЫМ

*Мәхмүт Хәсән истәлегенә*

Җаным тавышлардан тынып кала,
Сагышлардан сагая.
Танышларны таный алмый
Җан кадәр җан саргая.

Бер көнлек җыр, бер көнлек җир,
Минутлык кына фикер.
Җирсез, җырсыз, фикерсезне
Син күз алдыңа китер...

Ярсып ала, тынып кала,
Кача ул тавышлардан.
Яфрак түгел, җан саргая
Мәгънәсез ярышлардан:

Кемнең кесәсе калын да,
Кемнең түбәсе биек?
Кем кешедән «үсеп җиткән»
Һәм булган җанвар-киек?

Ерткаланган, кискәләнгән
Җир ята ыңгырашып.
«Җир, җыр!» — диеп җан атканнар
Тора хәер сорашып.

Хәер сорашып торган җан
Җан була аламыни?
Җанга кирә алмаган хан
Хан була аламыни?

«Ханбыз!» — диеп чаң кагалар,
Янгын, ә яна җаннар.
Янгыннар белән бутала,
Бутала инде таңнар.

Таң алдыннан тынып кала, —
Куркамы уяныргa?
Җан уянудан курыкмый,
Курка тик уйланудан.

Әгәр дә уйлана калсаң,
Шашып бетәргә була.
Илдән түгел, Җир шарыннан
Качып китәргә була.

Адәм мантыйгына сыймый
Уе да, гамәле дә.
Безне инде кабул итми,
Ахрысы, галәме дә...

Үз җиреңдә килмешәк син, —
Базары түбән җанның.
Сакчылар саклап торалар
Сатыла торганнарын.

Сатылмаганнар сакланмый, —
Дәрдмәнд ачтан интеккән...
«Ил корабы җан сорый», — дип,
Тарихка әйтеп киткән.

Шомарткан-шуган булабыз,
Боз ялап бызылдыйбыз.
Дөнья бозык, булмый узып, —
Бөгел дә сыгыл, дибез...

Барсының да сәбәбе бер:
Без — коллар әле һаман.
Коллык богавын өзәрлек
Баһадир табылмаган.

«Богауны өзәм!» — дип, халкым,
Өзелмәсме җан гынаң?!
Офык алсу, җаннар яна, —
Бутый күрмә таң белән.

## КИРӘК ИДЕ...

Кайгыга чумган иделәр,
Мин җыр башладым.
Иңнәренә баскан йөкне
Алып ташладым.
«Син кирәксең!» — диеп, мине
Кочып алдылар.
Мин җырлаган җырны бик тиз
Отып алдылар.
Аларга кайгы таратыр
Җыр кирәк иде.
Ә миңа башымны салыр
Җир кирәк иде...

## МИЗГЕЛЛЕК УЙ...

Мин уйсызмын, уйламыймын
Берни хакында.
Очып барам әле сәер
Хыял атында.

Сызылып кына таң атуын
Күрәм күрүен,
Болытларга ялгыз айның
Килеп керүен.

Әмма берни тоя алмыйм,
Җан хәрәкәтсез.
Яшәп буладыр ул болай
Бер һәлакәтсез...

Әлегә көз, соңгы яфрак
Ботак очында.
Юк, өзелеп төште инде,
Тотам учымда.

Көйдереп ала учымны,
Аһ, өшим, өшим!
Җанын ташлап чыгып китте,
Тапкандыр ишен.

Мин уйсызмын, уйламыймын,
Яфрак учымда.
Мәхәббәткә нокта куйдым,
Ахры, шушында...

Көз йөрәген учларыма
Салып киттең шул.
Йөрәгемне үзең белән
Алып киттең шул...

## БАШКА ЯЗМЫШ ЮКТЫР...

Зәңгәр нурлы, алтын кояш нурлы
Күгем гүя бүген күтәргән.
Авыр миңа — көннең болытларын
Күз кабагым белән күтәрәм.

Карлар түгел, зар түгелер төсле
Яшәреп лә аккан болыттан.
Минем җаным зар болыты белән
Кышкы яшеннәргә юлыккан.

«Зар яумасын җиргә, сабыр бул!» — дип,
Болытларны төйим җаныма.
Син җанымны кара болыт иттең,
Аяз чагын башка сагынма!

Җылы куллар тисә, яңгыр ява,
Салкын куллар тисә — кар гына.
Кояшларым бар да синең күктә,
Күңелемдә калган зар гына.

Зарларымны кыссам — җыр чыга,
Башка язмыш юктыр җырчыга.

## АРАЛА!

Кешеләрне шундый яраттым мин:
Җырлар багышладым аларга.
Җырладылар алар шул җырларны,
Моңнар акты сыймый ярларга.

Кешеләрне шундый яраттым мин:
Гафу иттем барысын аларга.
Алар шундый ямьсез кыландылар,
Нәҗес акты сыймый ярларга.

Кешеләрне шундый яраттым мин:
«Кер, — диделәр, — безнең арага».
Нәҗес тулы ярда басып торам,
Бата күрмим, Ходам, арала!

## БЕЗ — ДӨНЬЯНЫҢ ҖАНЫ

*Риза Ишморатка*

Дөнья сорый миннән: «Җаным,
Ризасыңмы, Ишморат?
Ходайга гариза бирдем,
Кыямәттән иш сорап».

«Җаным» дип ялгыш әйтми ул,
Без — җаны бу дөньяның.
Базарда да базары зур
Тик сатылмаган җанның.

# ҖӘЯҮЛЕ ҖАН

*Нажар Нәҗмигә*

Чәчләрең кара чагында,
Җаның яралы иде.
Яралы кош кеби җаның
Талпынып бара иде.

Күңелеңдә яра иде,
Ә дөнья бара иде.
Кулларыңда гармун гына
Сагыштан яна иде.

Яралы кош кеби җаның
Бер очты да бер төште.
Еллар ничек өлешеңә
Җәлләмәгән көмешне...

Күңел яктыларың шулай
Чыкты микән иреккә?
Ә күңелләр һаман бәйдә,
Гомерләрне биреп тә,

Алып булмады ирекне, —
Күңелләр һаман яра.
Яралы кош кеби җаннар
Очалмый җәяү бара...

## БАР!

*Әхсән Баянга*

Җан түрендә Такташлар бар,
Җанга иңгән якташлар бар.
Күңелемдә ак Сөннәр бар,
Җанга иңгән Әхсәннәр бар.

Гомерләрен күккә очкан
Ике аккош иткәннәр бар.
Мәхәббәтен, туган җирен
Мәңгелек җыр иткәннәр бар.

Ак Сөннәр бар, Әхсәннәр бар,
Җырны, җирне, мәхәббәтне
Коръән итеп әйткәннәр бар.
«Урланган ай»ны коткарып,
Милләтенә илткәннәр бар.
Бар!

## ҖАННАН ТОТЫП КЫСТЫ

*Илдар Юзигә*

Дөнья безне җаннан тотып кысты,
Без сыгылдык, бездән моң чыкты.
Бүген инде тотып кысты базар,
Чыгармакчы булып бездән зар.

Дөнья, синең ни икәнең беләм,
Сиңа охшап бөкерәеп киләм.
Әмма ихлас җаннан җыр чыга, —
Барып җитәчәк ул җырчыга!

## САБЫРЛЫКЛАР ТЕЛИМ

*Зөлфәткә*

Дустың китте,
Сыңар канат белән
Очалмаган коштай талпындың.
Син дә киттең,
Белмәдеңме шуны —
Син бит, шагыйрь,
Милләт иңендәге
Бер канаты идең халкыңның...

Йөрәгеңне синең былбыл чакты.
Еланны да хәтта сайраттың.
Былбыллы да, зәһәр еланлы да
Шушы җирне ничек яраттың!

Каләмеңнән фәкать сөю тамды,
Каләмеңнән тамды гүзәллек.
Сабырлыклар телим милләтемә
Синең китүеңә түзәрлек.

## ҮЗЕМ КЕРӘМ

*Роберт Әхмәтҗанга*

Җан фасылы
Ел фасылы түгел.
Ә бу гасыр минем
Языммы әллә,
Егерменче гасыр!
Кайсы гасыр язы
Мәңгелекнең
Капкаларын ачыр?!

...Якты елга булып
Агып керәм,
Ләйсән тамчылардай
Тамып керәм.
Гомер тирәгенең
Ботагыннан
Яфрак–яшьләр тама
Берәм–берәм...

Яшь елгасы булып
Керәм ташып.
Хис давылы булып
Үтәм шашып.
Фанилыктан туйдым,
Ачуланма, дөнья!
Мәңгелекнең капкаларын
Үзем керәм ачып.

# Ә КҮК ЭЗЛИ

*Фәннүр Сафин истәлегенә*

«Урман ничек шаулар?» — дигән идең.
Урман шаулый... авыр...
Яфраклары ничек шаулаганын
Ишетерме тамыр?

«Ишелмәсме таулар?» — дигән идең.
Ишеләләр таулар.
Син киткәннән бирле афәт илдә,
Тынып тормый даулар.

Урман «Фәннүрсезмен»
Дип шауламый.
«Бер былбылым, — ди, — ким».
Таулар да бит, былбылларын җуйса,
Моңаерга мөмкин.

Ә күк эзли ике зәңгәр күзне —
Синең күзләреңне.
Тауда үскән агач тамырлары
Илтсен сүзләремне:

«Урманнары синең җырны җырлый,
Әнә тыңлый таулар.
Җырларга да туплар атып тора,
Җырлар әле саулар!»

## ШАГЫЙРЬ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

*Рәшит Әхмәтҗанга*

**I**

— Кабереңне кояш күргән көннән
Халык саный икән сине үлгән.
Кояш күрмәсен дип, кабереңне
Таң атуга ап-ак карлар күмгән.

Язлар җиткәч ничек түзәрсең соң? —
Кеше сүзе авыр кагылыр бит.
Кабереңә килеп баш исә дә,
«Үлгән» диючеләр табылыр бит.

**II**

— Җәй җиткәч тә терелəм мин, бәгырь,
Җир өстенә алып чыгар үлән.
Җирдә җыр һәм үлән исән чакта
Әйтеп карасыннар: «Рәшит үлгән».

Мин бит монда, бәгырь, тик шулай дип
Көлгәннәрдән көләр өчен килгән.

## ҖАНДА ШУНДЫЙ ХӘЛЛӘР

Дөнья гади генә могҗиза ул,
Белә дөнья үзенә кирәкне.
Бер утларга, бер суларга сала
Нәни генә гыйсъян йөрәкне.

Дөнья гади генә могҗиза ул,
Белә кемдә нинди йөрәк бар.
Йә уйлата, йә җырлата аны,
Йә елата гомер буе зар.

Дөнья гади генә, гали, фани,
Яндыра да сала ләхеткә.
Өлгералсаң, тик җырларың кала,
Ярый җырлар кала, бәхеткә.

Җырдай гали, гади бу дөньяга
Яшәр өчен диеп киләбез.
Җыр калдырып китәр өчен генә
Килә җиргә шагыйрь, беләбез.

Дөнья бары җыры белән гали,
Акча белән түгел, беләбез.
Җырчыларның кадерләрен никтер
Җирләгәндә генә беләбез.

# ЭНДӘШӘСЕ КИЛГӘНДӘ

*Гөлчәчәк Галиевага*

Исмә әле, җил,
Тукта әле, җил, —
Өзмә гөлнең чәчәген.
*Халык җырыннан*

Хушлашмый да киткәнсең шул
Гөлчәчәкләр иленә.
Сагышларны төйим хәзер
Сезгә искән җиленә.

Минем эндәшәсем килә,
Миңа сездән сүз кирәк.
Күңел тәрәзләре аша
Карый торган күз кирәк.

«И-и, бала, — дигән сүз кирәк, —
Алай уйлыйсың икән.
Җаның — вулкан, бигрәкләр дә
Белеп дулыйсың икән».

Җанда атылган вулканны
Чыгармый торам түзеп.
Җан-болыннан Гөлчәчәгем
Җилләр китмәсен өзеп.

Соңлап чәчәк атканыңны
Җилләр дә тора сизеп...

# КӘҮСӘР МӘХӘББӘТ

*Якташым, шагыйрә Кәүсәрия Шәфыйковага*

Син җаныңны кош итеп тә
Күтәрәсең күкләргә.
Җирне кочкан җыр булып син
Яңгырыйсың күпләргә.

Сөю күгендә аккош син, —
Таныды сине парың.
Инде дөнья белә бүген
Кәүсәр мәхәббәт барын.

Син җаныңны ялгыз айга,
Кояшка да ташлыйсың.
Янып үлгән дисәләр дә,
Кабат яши башлыйсың.

Сөйләп торалар хәлеңне
Көнен — кояш, төнен — ай.
Безнең яктан искән җилләр
Бертуктаусыз пышылдый:

Сагышлардан сыгылмый ул,
Сагына гына белә.
Ул еламый, ул кояш күк,
Янган чакта да көлә.

## АЧЫГЫЗ ТӘРӘЗӘЛӘРНЕ

*Миләүшәгә*

Киләчәккә барасы бар,
Саубуллашыйк, ягез.
Ачыгыз тәрәзәләрне,
Булса тәрәзәгез!

*М.Әгъләм*

Шундый мизгелләр була, —
Гөрләп тора бар дөнья.
Ә синең күңел күгендә
Тукталып калган дәрья...

Тукталган агым, җилләре, —
Беркемгә кирәкмисең.
Туктамаска шул халәттә
Ышандыр йөрәкне син...

Акылның хөкеме хәтәр:
Юк, болай булмый яшәп!
Шул мизгелдә — бер могҗиза! —
Аяз күк китә яшьнәп...

Җан кылына: «Яратам!» — дип
Чиртеп ала бер заты.
Йөрәккә кан ташып керә,
Акыл хөкеме каты.

Йөрәгең кушканны эшлә.
Мин сиңа түгел җәллад.
Фәрман чыгарган идем тик
Йөрәкне генә җәлләп...

Ә җыр — җан агымы бит ул! —
Җырла да күч җаннарга!
Җаннардагы якты чыга
Кояш булып таңнарга!

Шундый мизгелләр була, —
Туктальп кала галәм...
Бер кәррә җан җылысыннан
Йөгереп китә каләм.

Синең җаныма дәшүең
Җан галәмем кузгатты.
Сөймәгәннәргә сүзем юк, —
Миңа кояш күз атты.

Кеше җанын тыңлый икән
Хәтта кояшның Үзе!
Шагыйрьгә кояштай кирәк
Җаны ачыкның сүзе!

Җаныгыз булса, ачыгыз! —
Кертегез сез җырларны!
Киләчәк бит сораячак:
Ул заманда җыр бармы?

Сугыш-җиңү, алтын түгел,
Мәхәббәт — вөҗдан һәм җыр —
Менә нәрсә әйттерәчәк:
«Булган, — диеп, — бөек чор!»

Ә син сөюгә мөкиббән,
Җаныңа җыр җыясың,
Милләтнең киләчәгенә
Бөек мизгел уясың!

## ӨМЕТ УТЫ

*Салисә Гәрәевага*

Шагыйрь яши
Милләтенең җанында,
Өмет дигән
Мәңгелек ут сагында.

Салисә, җитмешең белән! —
Зур хезмәт җимешең белән!
Яшеңнең дә, эшеңнең дә
Зур һәм җыр икәнен беләм!

Чит җирләрдә үзең булып,
Татар булып тору өчен,
Үлемне дә яшәештән
Башка юлга бору өчен,
Өметсезлек баткагыннан
Башкаларны йолу өчен
Кояш булып яну да аз, —
Бүләк иттең син шигъри наз.

Сүнеп барган җаннарга да
Керә алдың хисең белән.
Йөрәгеңдә янган утның
Шагыйранә көчен беләм!

Әгәр шулай һәрбер татар
Үз милләтен ярата алса,
Җанын ягып, кыйбласына
Милләтен карата алса,
Без башкача яшәр идек,
Татар булып яшьнәр идек...
Ә барыбер
    тамчы тишә лә бозны! —
Мәңге бакый
    сүндералмаслар безне!

Бездә өмет — мәңгелек ут!
Шайтаннарда өмет юк!

## КҮРМӘДЕ... КҮРМӘЯЧӘК!

Үсим генә тизрәк, шул чагында
Чага алмас усал кычыткан дип,
Буем җитәр, ачып керәчәкмен,
Чыгачакмын барлык ишектән дип
Ышанулар юкка гына булган.

Ачы сүзләр миңа кагылмас дип,
Тизрәк шушы чорны үтим генә.
Җәен түгел, хәзер ел әйләнә
«Кычытканнар» җанны үрти генә...

Күпме калды артта ишекләрнең
Үзем ачмый гына чыкканнары
Һәм сүзләрнең аяз күктән генә
Яшен уты булып сукканнары.

Булды, булды арттан килгәннәрнең
Сизмәгәндә китереп сукканнары,
Янәшәдә атлап барганнарның
Аяк чалып кына екканнары.

Арттан сукмый, аяк чалмый гына
Гөнаһсызга бәла якканнары,
Уен–көлке, шаян сүзләр сөйләп,
Кара елан булып чакканнары...

Булды, булды, вокзал идәнедәй,
Җаннарымны таптап чыкканнары,
Тормыш дәрьясында батыралмый
Мәхшәр утларына тотканнары...

Булды, әле ничек кенә булды
Бер кашык су белән йотканнары.
Мине сөеп оттырганнар булды,
Мине ташлап китеп отканнары...

Балачакның зәһәр кычытканы
Баскан икән бары кычытканны.
Чага дөнья, әмма күрмәде ул,
Күрмәячәк үзенә йөз чытканны!

VII

*Вакыт — хаким!*
*Буйсынмаганнар алдында*
*Ул да ятим.*

* * *

Вакытыңны сакла, диләр —
Ни файда?
Вакытны тотып калалган
Зат кайда?

Вакытыңны саклап торма,
Хаклап тор!
Һәр минутның киләчәген
Яклап тор!

## СИКЕРӘ БҮГЕН АЛТЫН

Тауга карап тау булмассың,
Эчеңдә алтын юктыр.
Вулкан булып атылырлык
Җаныңда ялкын юктыр.

Тауга карап кеше бул син,
Һич табынма алтынга.
Утны буйсындырам диеп,
Кермә, юләр, ялкынга.

Утка тимә — яндыра,
Алтын җансыз калдыра.
Җан кердеме алтынга,
Яшәү бетә халкыңа.

Сизәм, терелергә теләп,
Сикерә бүген алтын.
Хәер сорап тора шуңа
Уйлы да моңлы халкым.

## МӘҢГЕЛЕКНЕ ЭЗЛИМ

Ярдан ярга бәреләдимәгез лә,
Без ярларда бәргәләнәбез.
Яшәү белән үлем арасында
Мәңгелекнең барын беләбез.

Күз күрмәслек, бәлки, атомдыр ул,
Тоялмаслык, бәлки, нурдыр ул?
Колак ишетмәслек, ә барыбер
Җанга иңәр назлы җырдыр ул.

Ярдан ярга бәреләдимәгез лә,
Мәңгелекнең эзлим чаткысын.
Өмет уты сүнгән чаклар була,
Мин шул сернең тоям яктысын.

Бер төндә дә кырык үлеп терелэм
Мәңгелек җыр туар ноктадан.
Үлмәс җырның агымына керми
Мин яшәүдән әле туктамам.

Төннәр буе мин шул җырны эзлим,
Калдырырга яшәү ярында.
Үлем ярын чигендереп була,
Җанда шундый җырың барында.

Ярдан ярга бәреләдимәгез лә,
Җырдан җырга гына күчәм мин.
Яшәү белән үлем арасында
Мәңгелек җыр табу исәбем.

* * *

Вакыт — хаким!
Буйсынмаганнар алдында
Ул да ятим.

Вакытларга буйсынмаган, әйт, кем соң бар?
Шушы хакта ак уй булып ява карлар.
Ак карларны җылыта уй, — язлар килә.
«Бер мизгеллек хаким сез», — дип,
Сулар булып челтер-челтер вакыт көлә...

## ЧҮПРӘК ФӘЛСӘФӘСЕ

Алтын бәһасе, һай, үзгә, —
Менә дә төшә.
Шундый түбән тәгәрәде
Ул тагын кичә.

Ә мин — чүпрәк кенә инде,
Мин очсызрак.
Бәндәне чүпрәк бизидер,
Агачны — яфрак.

Кешене тугач та кем соң
Алтынга төрә?
Кәфенгә төренеп, кеше
Гүренә керә...

* * *

Ташла суга — туп батмый.
Таш төпкә төшә — акмый.
Юкса таш та туп кадәр,
Төптә яткач, юк кадер.
Төшкәнсең икән төпкә,
Чөярләр диеп көтмә!
Тик дәрьяны кичерсәң,
Тик дөньяны кичерсәң,
Чыгарсың килеп өскә,
Димәк, син ия көчкә,
Бар дөнья табынырлык,
Тузан булып җилгә очып
Беткәч тә сагынырлык!

## БАРМЫ ДАРУ?

Мин яшәүдән арыганмын.
Юк, түгел шул яшәүдән.
Яшәмәүдән арыганмын
Һәм ихлас сүз дәшмәүдән.
Кысылудан арыганмын,
Күңелләр тарлыгыннан.
Күпләрнең качасы килә,
Түгел татарлыгыннан!
Үзе булып яшәмәүдән
Арыды инде җаннар.
Җансыз гына шуышалар
Фани дөньядан саннар.
Туры сүзгә турсаялар:
«Рәнҗедек», — диләр хәтта.
Ышандыру мөмкин түгел,
Антлар эчсәң дә Хакка.

Бу арудан дәва бармы?
Бар микән дарулары?

Бу җанымның саннарында
Соң чиктә барулары...
Көн артыннан көннәр үтә,
Ә ник шатлыкка түгел?
Үз-үзеңнән киткән саен
Тарая бара күңел.
Кысыла җан, кысыла аң,
Үз-үзеңнән киткәнгә,
Җанда туасы ирекне
Читтән өмет иткәнгә.

Дару билгеле күптән, —
Ай әйтеп тора күктән:
Милләт язмышы җирдә
Хөррият сөяр ирдә!

## ХАЛӘТ МАНЗАРАСЫ

Август башы гына иде әле,
Агач төпләренә сары инде.
Яфракларның көчсез иркәсен
Челлә өзде, ни хәл итәсең...

Инде сентябрьнең көне җитте, —
Күчмә кошлар юлга җыена.
Яшел дәрья булып яткан урман
Сары сагышларга коена.

Шомырт, зирек комач кызыл төстә,
Урман сары, соры, яшел дә...
Көзге күкрәү булып хушлаша җәй, —
Яшьнәп ала әле яшен дә...

Табигатьтә сынау арты сынау, —
Соңгы чәчәкләрне үбә кар...
Көзгеләрдә күреп кенә булмый, —
Күңелләрдә шундый халәт бар...

## ҖИЛ ҺӘМ ТАМЫР

Дөнья елый...
Әгәр күз яшьләре
Була калса коеп яуган яңгыр,
Яфрак кадәр йөрәк хәлен аңла,
Әнә яфракларга ничек авыр...

Өзәргә дип хөкем иткән көзе,
Өзелмәскә фәрман бирә тамыр.
Җирдә җылы бар, тик көзге җилләр
Салкыныннан җанга ничек авыр...

Дөнья елый, каен түгә яшен.
Сары яфрак түгеп елый көзе.
Ничә генә көзнең авырлыгын
Күтәралыр икән җаным үзе?..

Җанга коеп көзге яңгыр ява.
Яфрак кадәр йөрәк хәлен аңла...
Сары сагышларын йөрәгенә
Һәр көздә җир шулай җыеп ала.

* * *

Кимсетергә, ким итәргә
Тырышалар булганны.
Киметеп тә, арттырып та
Булмый шул булмаганны.

## БАР ИКӘН

Дөнья күзгә моңга талып ауган, —
Сукмакларга сары кар яуган.
Кыштыр-кыштыр яфрак карлары, —
Бу аларның соңгы җырлары.

Күзгә җилне шундый кызганам мин, —
Җан алулар бигрәк кыендыр.
Күзгә җил язмышын насыйп итмә, —
Утта, суда, комда коендыр...

Җил ул — үле яфрак күтүчесе.
Сулган, үлгән күптән китүчесе.
Кыштыр-кыштыр яфрак карлары, —
Бу аларның соңгы зарлары.

Әйтерсең лә җирдә алтын келәм, —
Кояш үзе тора күнләшеп.
Җирдән күчле булса, яфракларны
Алыр иде үзенә эндәшеп.

Җирнең кояшка да буйсынмаган
Мизгелләре әле бар икән...
Күз дип атлап барган сукмагымда
Яфрак түгел, күптән кар икән...

## ӘЙЛӘНЕШ

Агач өсләренә ятып,
Ябышып кала ак кар.
Барыбер егылып төшә, —
Ботакта бөреләр бар.

Өй түбәләренә ятып,
Кыш буе тора ак кар.
Шуышып төшә түбәнгә, —
Каргалар кайтыр чаклар.

«Күктән дә сөрелдем, — ди кар, —
Җирдән дә сөрелдем, — ди, —
Юкка гына мин Җир кадәр
Биеккә үрелдем», — ди.

Китә тагы диңгезгә,
«Рәхмәт, — дип, — җирегезгә!»

* * *

Әгәр җанга көя төшсә,
Көяләндерә.
Көя кортын җан гынаңа
Ияләндермә!

Кискәли, көрпә ясый ул,
Тәмам он итә.
Җанны җан түгел, ахырдан
Сансыз ком итә.

## ЮКСА...

Алмаз хакы төшә, диләр,
Тау–тау матдә озакламый
Кояш нурлары астында
Алмаз булып пешә, диләр.

Алтынын да, көмешен дә,
Кояшкаем, пешер әле!
Шуларга табынганнарны
Урынына төшер әле!

Чүп тавыдай җир өстендә
Ятсын көмеш, ятсын алтын.
Юкса шулар, җанга иңеп,
Иблис итте җирнең халкын...

* * *

Тула күңел, түгелә.
Күз яшьләре тоз гына.
Кагылма өшегән җанга,
Йә уалыр боз гына.

Ничек сәер яшәлә,
Җан кителә, чәчелә.
Куна көмеш чәчеңә,
Карамый да яшеңә.

## САГЫШ

Сагыш ни ул? —
Кәррә җил дә
Юк чакта көзге көндә,
Яшәвенең соң мизгеле —
Күбәләк елый гөлдә...
Сагыш ни ул? —
Көзге күкне
Каплаган соры болыт.
Кыр казлары китеп бара
Өзелмәс чылбыр булып...

Сагыш ни ул? —
Аккошларын
Озаткан күл күзедер.
Күзе түгел, тирән, тирән
Сагышның ул үзедер.

Сагыш ни ул? —
Аерылумы?
Ялгызлыгымы җанның?
Бу халәт — туктап калуы
Туарга торган таңның...

Сагыш ни ул? —
Җанның нечкә
Кылында уйналган көй.
Туган туфрак, сөйгән ярың,
Туган телең ачкан өй...

Югалтсаң
Шул өчнең берен,
Баскан җирең убыла.
Югалту туфаны баса,
Бетмәс сагыш шул була.

## КӨЗНЕҢ БЕР КӨНЕ

Күкне күк болыт каплаган, —
Шундый да калын!
Җил котыра, бәргәләнә, —
Оныткан ялын.

Исенә төшкән, яңгыры
Түгелә генә.
Әйтерсең бар да җыелган
Бүгенгә генә.

Сыгыла-бөгелә шаулый тирәк,
Болытлар ага.
Яшел яфраклар өстенә
Карларын кага.

Бер көндә — җил дә, давыл да,
Яңгыр, буран да...
Көзне җибәрәсем килми
Торам урамда.

Яфрак очларыннан тып-тып
Тама кар суы.
Карлар хәтерендә калган
Язлар ярсуы.

Кар хәтере болытларны
Ничек тиз куды!
Тик соң иде, зәңгәр күктә
Салкын ай туды.

Һәм... барысы да бер көндә,
Бары бер көндә! —
Яфракларны коткаралмас
Инде беркем дә...

## КӨЗГЕ УРМАН

Шәрә тирәкләр гаскәре
Сары диңгездә йөзә.
Төйнәлгән бөреләр инде
Кышның сулышын сизә.

Соңгы яфраклар җилсез дә
Келт итеп өзеләләр.
Соңламыйк китәргә диеп,
Кошлар да тезеләләр.

Гөмбә ташый әле керпе,
Тиен куыштан карый.
Яфраксыз тирәк чирүен
Салкын җил генә тарый.

* * *

Хәсрәт керсә җанга,
Кояш түгел, ут шары
Тәгәрәп чыга таңга.

Җанга сөю иңсәме,
Чыгам диеп ике канат
Төртеп тора иңсәне.

Хәсрәт утыра төпкә,
Канатлар үсеп чыга да
Бәхетле оча күккә.

Мәхәббәт барсын җиңә, —
Зурмын дигән хәсрәте дә
Үз кабыгына иңә.

## КАБАТЛАНМАУ

Көзге урман.
Моңсу тынлык.
Сары яфраклар җирдә.
Ә ничек шаулады алар! —
Китмәстәй иде бер дә...

Ул җырлар нинди иделәр! —
Отып алды Иделләр.
Дулкыннар да ул җырларны
Онытмастай иделәр...

Иделдә көз.
Су өстендә
Дулкыннар йөгерешми.
Яфракларның соңгы җыры
Иделләргә ирешми...

Язларда ташыр Иделләр,
Ямь-яшел булыр урман.
Ачып кына карый алмам,
Өсләремдә җир-юрган...

## ТӨН ТҮГЕЛ...

Тукта әле, уй агымы!
Туктал бары минутка!
Җанымны ташлаган идем
Уйсыз чакта мин утка...

Уй йомгагының җеп очын
Бер ычкындырсаң кулдан,
Гыйсъян йөрәк әзер тора
Чыгып китәргә юлдан.

Тукта, уй! Туктачы, Вакыт! —
Кермә җанымны ватып.
Шушы яшькәчә сөюне
Карамаганмын татып.

Йөрәк акылга буйсынмый,
Җаным буйсынмый санга.
Йөрәк читлеген, җан санын
Ташлагач, килдем аңга...

Караңгы төшкәнме дисәм,
Мин икән инде анда...
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Тыңламады шул акылны
Йөрәге дә, саны да...

# ЭЧТӘЛЕК

## I

«Кан бар, җан бар...» . . . 6
Болгар белән сөйләшү . . . 6
Төен . . . 9
Үз ягына бора . . . 11
Булуы кыйммәт! . . . 11
Әверелеш чоры . . . 12
Яңа ГУЛАГ . . . 12
Өмет көнен билгеләү . . . 14
«Бала туа, тибрәтергә җыр кирәк...» . . . 15
Илегү . . . 16
Дулкын кирәк . . . 17
Иң олы корал . . . 18
Котлыйм . . . 21
Төрмәләр һәм парламентлар... . . . 22
Белү кирәк! . . . 23
Кош һәм кеше . . . 24
Элек һәм хәзер . . . 24
Саннан үч алу гына . . . 25
Уянгач аңларсыз... . . . 26
Чүп үләне . . . 27
Сабырлык . . . 27
«Без дә китеп барабыз ул...» . . . 29
Моң юлы . . . 29
Константа! . . . 30
Кычкырам! . . . 31
Дөнья Кеше көтә . . . 33
Чыгу юлы . . . 34
Калкына . . . 35
Хәтере кайтканнарга . . . 36
Хыял һәм чынбарлык . . . 38
Әлегә башкача . . . 39
Әгәр кайтсам... . . . 40
Буталыш . . . 41
«Җир тудырган һәрбер нәрсә...» . . . 42

## II

Безнең авыл . . . 44
Барасым бар... . . . 45
Без булмасак... . . . 45
Яңавылда туып үскән без . . . 46
Хәлем шундый... . . . 48
«Калганга да, киткәнгә дә авыр...» . . . 49
Кыр казлары ни дип кычкыра? . . . 49
«Авылыннан китсә дә кеше...» . . . 50

Еракта — йөрәктә . . . . . . . . . . . . . 50
Җир йөрәге . . . . . . . . . . . . . . . 52
Әгәр шулай булса . . . . . . . . . . . . 52
Икеләнү . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Төнге васыять . . . . . . . . . . . . . . 53
Чалгы чыңы . . . . . . . . . . . . . . . 55
Әнкәм өне . . . . . . . . . . . . . . . 56
Кыр казлары артыннан . . . . . . . . . . 58

III

Тукайга дәшү . . . . . . . . . . . . . . 60
И-и, Тукайҗан! . . . . . . . . . . . . . 62
Туган тел — намаз . . . . . . . . . . . . 64
Егылмасын, югалмасын дисәң... . . . . . . 65
Тукай кабат туар . . . . . . . . . . . . 66
Искә алу көнендә уйлану . . . . . . . . . 67
Фикерлене күтәрә алсак... . . . . . . . . 68
Тукайчарак безнең заман . . . . . . . . . 70
Туган телем . . . . . . . . . . . . . . 72
Ә иртәгә . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Ул кайтты мәңгелеккә . . . . . . . . . . 76
Үзгәрмәгән әле безнең җыр . . . . . . . . 77
Татар тагын йоклый . . . . . . . . . . . 79
Барлау . . . . . . . . . . . . . . . . . 80

IV

Их, син булсаң янда... . . . . . . . . . . 82
Ялгышмыйча ялгыштык . . . . . . . . . . 83
Чаралары юк иде . . . . . . . . . . . . 84
«Кагылма җанга, кагылсаң...» . . . . . . . 85
«Син мине кол иттең...» . . . . . . . . . 85
Әгәр белсә... . . . . . . . . . . . . . . 86
Ишетәсеңме?.. . . . . . . . . . . . . . 86
Көчлерәк... . . . . . . . . . . . . . . . 87
Ник кагылдың? . . . . . . . . . . . . . 87
Төшләр эзләп кайтам . . . . . . . . . . 88
Синнән миңа... . . . . . . . . . . . . . 89
Синең җаның . . . . . . . . . . . . . . 90
Ди-ва-на! . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Сагыну . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Төштәге бәхет белән . . . . . . . . . . . 91
Сиңа да, миңа да . . . . . . . . . . . . 93
Мин генә . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Ул чакта да... . . . . . . . . . . . . . 94
Синле фасыл . . . . . . . . . . . . . . 95
Гыйсъян тынлык . . . . . . . . . . . . . 96
Бар әле . . . . . . . . . . . . . . . . . 98

Ахыргача көттек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
Гомерлек гомер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100
Ул киткәч... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Эңгер–меңгерле сәгать . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Зөлфәт–Мөдәррис . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Ә таң атты... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
Үр һәм гүр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Уй дулкыны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Ни сөйләр Мөдәррисең... . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
«Мин сине бары дөньядан...» . . . . . . . . . . . . . . . 109
Йөрәк гөле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Мин ышандым кошка... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Кайта икән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112

## V

Ычкынасым килә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Нәни гашыйк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Кая ул... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Көткәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Мәхәббәт төтене . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Чишелү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Табышмак түгел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Мин сөйдем... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Карлар да белми . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Кунак мизгел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Үзгәрми үзгәртәләр... . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
Көнләшү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Җан һәм ялгызлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Башка чара юктыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Мәхәббәткә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Сукырайта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Синме, сөю? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Соңлаган мәхәббәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Яшим әле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130

## VI

Кояш белән сөйләшү . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
«Күк шәмәхә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Мин кемнеке? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Яшьлеккә дәшү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Тыңлагыз бу мәдхияне . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Җаным . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Кирәк иде... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Мизгеллек уй... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
Башка язмыш юктыр... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Арала! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143

Без — дөньяның җаны . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Җәяүле җан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Бар! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Җаннан тотып кысты . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Сабырлыклар телим . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Үзем керәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Ә күк эзли . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Шагыйрь белән сөйләшү . . . . . . . . . . . . . . 149
Җанда шундый хәлләр . . . . . . . . . . . . . . . 150
Эндәшәсе килгәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Кәүсәр мәхәббәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Ачыгыз тәрәзәләрне . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Өмет уты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Күрмәде... күрмәячәк! . . . . . . . . . . . . . . . 156

**VII**

«Вакытыңны сакла, диләр...» . . . . . . . . . . 158
Сикерә бүген алтын . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Мәңгелекне эзлим . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
«Вакытларга буйсынмаган...» . . . . . . . . . 160
Чүпрәк фәлсәфәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
«Ташла суга — туп батмый...» . . . . . . . . . 161
Бармы дару? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Халәт манзарасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Җил һәм тамыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
«Кимсетергә, ким итәргә...» . . . . . . . . . . . 163
Бар икән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Әйләнеш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
«Әгәр җанга көя төшсә...» . . . . . . . . . . . . 165
Юкса... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
«Тула күңел, түгелә...» . . . . . . . . . . . . . . 166
Сагыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Көзнең бер көне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Көзге урман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
«Хәсрәт керсә җанга...» . . . . . . . . . . . . . . 169
Кабатланмау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Төн түгел... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171

Литературно-художественное издание

**Сафина** Назибя Ахматнуровна

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

На татарском языке

**ПАМЯТЬ КРОВИ**

Әдәби-нәфис басма

**Сафина** Нәҗибә Әхмәтнур кызы

**КАН ХӘТЕРЕ**

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.Н.Мусина*
Корректоры *Л.З.Шиһапова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 16.10.2009.
Форматы 75×90 1/32. Шартлы басма табагы 6,88.
Тиражы 2000 д. Заказ В-1516.

Татарстан китап нәшрияты ДУП.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.